Рәшит Ягъфәров

# Тулпар моңы

*Шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006
УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Я22

**Ягъфәров Р.Ф.**

Тулпар моңы: Шигырьләр/Рәшит Ягъфәров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 143 б.
ISBN 5-298-04175-2

Әлеге китапка авторның төрле елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-04175-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Ягъфәров Р.Ф., 2006

## ЯЗМЫШЫМ – ШИГЫРЬЛӘРЕМДӘ

Тәңрем миңа үзгәреп торучан холык биргән. Бәлки, бу минем Сукояр йолдызлыгы астында тууымнан килә торгандыр? Белмим.

Дуслар миннән кайчак, гаҗәпләнеп: «Кем син?» – дип сорыйлар. Кайчакта үткән гомеремә әйләнеп карыйм да, гаҗәпләнеп, үземә-үзем дә шундый ук сорауны куям: «Кем мин – фольклорчы-галимме, сәясәтчеме, укытучымы, журналистмы, әллә шагыйрьме?»

Хәер, әдәбият җене миңа бала чакта ук кагылган иде. Эш «драматург» булудан башланды. Туган авылым Күчтәнти Башта, Пермь урманнары уртасында Урал тауларына посып кына утырган 20—25 йортлык кечкенә авылда, без ишле гаиләдә үстек. Кечкенә генә клубыбызда театр куярга ярата идек. Әмма балаларга яраклы пьесалар табалмыйча аптырыйбыз. Шунлыктан миңа, боларны оештыручы кешегә, «драматург» булырга туры килде. Әдәбият белән кызыксынуым шул чорларда башланды шикелле.

Бервакыт безнең спектакльләр куя торган клубыбызга – амбарлар җитешмәгәндер инде – урып-җыю вакытында солы салдылар. Мин бу хәлгә бик нәфрәтләндем һәм «Колхоз юлы» газетасына шул хакта мәкалә язып җибәрдем. Аны бастырып чыгардылар һәм шул вакыйгадан соң колхоз рәисе белән мин, «ялкынлы журналист» арасында чарпылышулар да булып алды. Минем журналистика белән мавыгуым шул вакыйгадан башланды, ахрысы.

Бервакыт күршем һәм туганым Гөлҗиһанны укытучылыкка укырга җибәрергә булдылар. Моны белгәч, минем көнчелегем килде. Ничек инде Гөлҗиһан укытучы була да, мин гади бер журналист яисә язучы булып калам? Ә укытучыларны мин үз-үземне белә башлаганнан бирле илаһи затлар итеп күз алдына китерә идем. Киттем шулай Оса педагогия училищесына укырга... Укытучылыкка беренче адымнарым шуннан башлангандыр дип уйлыйм.

Педучилищеда укып йөргән чорымда күңелемә тагын бер «җүләр» уй килде: биюче булырга! Бу уй байтак тынычлыгымны алды минем. Класста укулар бетүгә, парталарны бер урынга җыеп урын ясыйм да хәлдән тайганчы биим дә биим. Белмим, кайчанга кадәр азапланыр идем, әгәр дә бер таныш врач белән сөйләшмәсәм. Ул миңа: «Рәшит, синдә «аю табаны» бит, плоскостопие – яхшы биюче була алмассың», – диде. Шуннан соң гына миндә «Мәхмүт Әсәнбаев» булу теләге сүрелде. Әмма биергә яратуым гомерлеккә калды...

Кайбер кешеләр минем фольклорчы булуымны, байтак кына халык иҗаты җыентыклары, фәнни китаплар чыгаруымны беләләрдер. Ул шөгылем каян башланды соң? Әлеге дә баягы шул бәләкәй генә туган авылымнан. Безнең авылда әкият-риваятьләр белән чынбарлык бергә яши иде. Мин әле хәзер дә Гөлчәчәкнең кайсы яланнарда йөргәнен, Аждаһаны болыт кайсы саздан алып киткәнен күрсәтә алам. Халык иҗаты белән аерылгысыз кеше булуым, Казан дәүләт университетына укырга кергәч, кабат «бәреп чыкты». Хәтерлим, беренче курсны бетергәч, безне Курган ягына фольклор экспедициясенә алып киттеләр. Шунда халыкның талантына исләрем китте: йөзәрләгән җырлар, бәет-мөнәҗәтләр язып алдык. Икенче курста кышкы каникул вакытында, дусларымны да «кодалап», тагын шул якларга экспедициягә киттек... Фольклорчы булуымның башы шуннан башлангандыр.

Балачакта сәхнә белән кызыксынуым турында әйткән идем. Соңрак бу морадыма ирешә язып калдым. 1967—1969 елларда, Казан дәүләт университеты белән беррәттән, татар сәхнә ветераны Кәшифә Тумашева, Касыйм Шамил, Асия Масаутова, Екатерина Гарданова һ.б. оештырган кичке театр студиясен дә тәмамладым. Остазларыбыз бу студияне рәсми рәвештә теркәп, кулга документ тоттыра алмасалар да, актерлык сәнгатенең бөтен серләренә дә төшендерделәр, һәм безнең күбебез профессиональ сәхнәгә юл алды. Мин исә, кызыксынуларым төрле юнәлешләрдә булган таркау кеше, университет биргән белгечлек буенча китәргә булдым. Шулай да «Ленфильм» төшергән «Моабит дәфтәре» дигән фильмда эпизодик роль уйнарга, үземнең туган ягыма кайткач, Барданың «атказанган артисты» булып йөрергә насыйп булды.

Кино белән кызыксынуым дәвам итте. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләү дәверендә фольклор экспедицияләрендә халык уеннарын кинога төшерү белән мәшгуль булдым.

Мине иҗтимагый хәрәкәттә катнашучы, Татар иҗтимагый үзәге, Бөтентатар «Мәгариф», «Мәдәният» берләкләрен оештыручы һәм җитәкчеләренең берсе дип белүчеләр дә бардыр. Бу эшләрнең тамыры балачакта түгел. Монысы инде минем иман белән бәйләнгән.

Фольклорчы буларак, миңа татарлар яшәгән төбәкләрдә күп йөрергә туры килде. Татарның кайда да кимсетелеп, кыерсытылып яшәве миңа нык тәэсир итте. Милләтне бу хәлдән чыгару юллары турында уйлап, газапланып яшәдем. Хәтерлим әле, 1989 елда Татар иҗтимагый үзәгенең беренче корылтаен азан белән башлап җибәрдек. Шул чакта минем күңелемдә әллә нәрсә өзелде, күзгә яшь бәреп чыкты һәм мин шунда үземнең милләт язмышы белән аерылгысыз булуымны аңладым кебек. Күңелемдә иман яңарды һәм ул җаным белән бергә генә чыгар инде, мөгаен.

Шулай төрле эшләрдә эшләп күп гомерем узып та киткән. Байтак шөгыльләр, вазифалар баштан кичкән: гәзитче һәм радиожурналист та, урта һәм югары мәктәп укытучысы да, кафедра мөдире дә, фәнни хезмәткәр дә, җәмәгать оешмалары җитәкчесе һәм башкалар да булынган. Әмма алар барысы да үзем яратып башкарган эшләр. Мин аларның барчасына күңелемне салдым, гомеремне багышладым. Әле, форсат булса, алар буенча олырак гамәлләр дә кыла алырмын шикелле.

Ә шигърият исә минем даими «чәчәгем». Мин аңа әле мәктәп укучысы чакта ук «кунган» идем. Хәтерлим әле, минем беренче шигырьләрем ни өчендер гел бәхетсез мәхәббәт турында гына була торган иде. Бервакыт мин ул әсәрләрнең барысын җыеп Сараш интернатының миченә тыгып яндырдым. Мәгънәсе шул: Һади Такташ та шулай иткән, имеш, чын шагыйрь шундый булырга тиеш... Шул көннәрдән бирле шигырь мине ташламый. Дөрес, миңа, «чуар йөрәкле» кешегә, гел шигърият белән генә шөгыльләнергә туры килмәде. «Коеп куйган шагыйрь» булып кына яшәү насыйп булмады. Ләкин «шигырь чире» мине вакыт-вакыт «якамнан ала» килде. Шигырьләрем азлап кына булса да языла, җыела торды, басыла барды. Ә туган төбәгем Бардада, 50 яшем тулганда, якташларым «Тулпарларым» дигән шигырь китабымны чыгарып, миңа бүләк ясадылар.

Шигырьләремнең сыйфатына килгәндә, берни дә әйтә алмыйм. Анысы турында укучым үзе хөкем итәр. Ә эчтәлекләре минем тормыш юлым белән турыдан-туры бәйләнгән. Анда минем язмышым, уйларым, хыялларым.

Гомерләр чапкан атлар-тулпарлар кебек тиз уза икән. Менә инде 60 яшькә дә ирештек. Хисап тотар вакытлар да җитеп килә. Аллаһы Тәгалә нәрсә биргән, дөньялыкта ни эшли алганмын – барысын да «тапшырып», «хисабын биреп» китәргә тиеш адәм баласы. Шуны телим: бу китап шигърият өлкәсендә биргән хисапларымның соңгысы булмаса иде.

*Рәшит Ягъфәров*

## Тулпарларым

Ыргылырга торган тулпарлардай,
Күңелемдә күпме уй ята.
Башны салып йокымсырап китсәм,
Шул тулпарлар кешнәп уята.
Сикереп торсам, тулпарларым киткән,
Дага чыңы калган юлларда:
Мин шуларны куып чабам, чабам,
Кулым изәп туар елларга.
Гомер буе чабам...
Кар-бураннар,
Җил-давыллар минем юлдашым.
Егылып калсам, очкан тулпар итеп
Ясасыннар минем гүр ташын.
Ир-егеткәй белән ат башына
Тәңрем белгәнниләр бирәсен.
Тулпарларга – канат,
Миңа исә
Тулпар җанын биргән, күрәсең.

*1969*

## Рәхмәт, җырларым...

Идеалларга таба китеп барам,
Йөзне кисеп ачы җил исә.
Ярый әле җырлый беләбез без,
Нишләр идек шунда югыйсә.
«Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...»
Упкыннарга егылып төшәр мәлдә,
Шундый җырлар өскә күтәрә.
...Канатыгыз белән кыйный-кыйный
Бу дөньяның бөтен моң-зарын,

Мине һаман күккә аштырасыз,
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, җырларым!

*1971*

## Сау бул инде, балачагым

Сау бул инде, балачагым,
Еракларга китәм мин.
Утыр әле янымарак,
Бер серләшми китлмыйм.
Мәңгелек дуслар булып, без
Айрылмас идек тә бит,
Бөркет баласыдай йөрәк
Ашкына биеккә дип.
...Сау бул инде, балачагым,
Еракларга китәм мин.
Бир әле кайнар кулыңны,
Бөтен гомергә җитәрлек
Җылысын алып китәрмен.
Еракларга китәм мин...

*1967*

## Карт диңгезче җыры

*Укытучыларыма*

Карт диңгезче белән ак көймәгә
Җилкән тарттык диңгез ярында.
Дулкыннарга кушылып әйтте картым,
Ярдан аерылган чагымда:
– Диңгез ярсу, улым, һәлакәтле,
Очырар давыл, очырар шторм.
Кара аны, яннан бәрмәсеннәр,
Дулкыннарга каршы бар, улым!
...Мин диңгезгә чыктым.
Туктап калсам,
Күреп алда җилен, давылын,
Ерак ярдан карт кычкыра сыман:
– Дулкыннарга каршы бар, улым!

*1967*

## Ялгыз нарат

Гасырлардан килгән мирас кебек,
Нарат тора юллар чатында.
Төпләренә ятып хәл җыям мин,
Юллар гизеп арган чагымда.
Җилдә шаулый-шаулый, ялгыз нарат
Нидер көйли, сөйли кич-иртән,
Гүя шунда узган гасырлардан
Бабамнарның тавышын ишетәм:
«Япан кырда берьялгызың тору,
Ай-һай, туган, авыр эш икән.
Гомерләрең тыныч узсын дисәң,
Үз ишләрең белән үс икән.
Күпме давыл күрдек,
Күпме яшен...

Энәләрем һаман яшелләр.
Зилзиләләр ялгызларга тия,
Биекләргә суга яшеннәр».
...Без китәрбез җирдән,
Нарат калыр
Мирас булып туар буынга.
Ял итәргә килгән оныкларга
Ниләр көйләр безнең турында?

*1967*

## Кул бирәбез

Кул бирәбез кешеләргә
Аерылганда,
Күрешкәндә,
Килешкәндә...
Кул бирәбез кешеләргә,
Олы бүләк биргән кебек,
Яп-ялангач кул бирәбез.
Без беләбез:
Шушы куллар
Назлый ала,
Саклый ала,
Яклый ала,
Һәлакәттән саклый ала.
Усал куллар булганын да беләбез без:
Канлы куллар,
Комсыз куллар,
Салкын куллар,
Хәнҗәр тоткан
Куллар барын беләбез без.
Андыйларга пакь кулларны бирмәдек һәм
Бирмәбез без.
...Кул бирәбез дус-ишләргә
Аерылганда,
Күрешкәндә,
Килешкәндә...
Без бит шулай
Уч тутырып
Бәхет өләшәбез кешеләргә.

*1968*

## Олы юл тузаннары

*(Элегия)*

Олы юл тузаннары
Күтәрелә дә күңелгә
Төшерә узганнарны.
Олы юл тузаннары,
Белмисезме кырык бердә
Җырлашып узганнарны?
Истә бит, истә әле дә
«Көт» дип кул сузганнары.
Юлга карап талчыктылар
Минем күз алмаларым.
Күтәрелде дә тузаннар

Йөрәкне алдалады,
Ә күзләр алданмады.
Күңел көтте, өмет итте,
Юллардан күз алмадым.
Юлларда ул күренмәгәч,
Еладым, түзалмадым.
Олы юл тузаннары,
Белмисезме кырык бердә
Җырлашып узганнарны?

*1967*

## Туган илнең ап-ак нигез ташы

Туган илнең ап-ак нигез ташы
Гел агарып тора күңелдә.
Шул агарып торган ташны уеп,
Кайнар яшем күпме түгелә.

Кичләр җитсә, истәлеккә чумып,
Мендәр итәм нигез ташларын.
Төшләремдә томырылып чапкан
Акбүз атлар күрә башладым...

*1968*

## Агымсулар моңсулата...

Чит илләрдә агымсулар
Илләргә таба ага.
Агып китәсе иде дә,
Дулкыны ярга кага.
Ап-ак каен басмалардан
Мин аңа гөлләр салам.
Гөлләрем ага да китә,
Мин һаман ярда калам.
Агымсулар моңсулата
Туган илләргә агып.
Гөлләрне ала да китә,
Үземне ярга кагып.

*1968*

## Илне сагыну

Туган илдән искән җилләрем дә
«Әллүки»не килеп сызгыра.
Кирәк икән шунда ятып ела
Йә йөрәктән сабырлык сора.
Җылысы юк баскан җирләремнең,
Ә чәчәкләр җыйсам, исе юк.
Бала чактан уйнап-көлеп үскән
Яшьлек дусларымның ише юк.
Туган ил җилләре «Әллүки»не
Сызгыра да һаман сызгыра.

Минем күңелем сыман буш урамда
Сары яфракларны туздыра.

*1968*

## Кайтыр юлда ап-ак томан

Кайрылып-кайрылып карыйм
Туган илләргә таба.
Күрер дә елар ди микән,
Юлларны томан яба.

Чәчләремнән юллар салып
Көтәдер газиз анам,
Көйлидер яшьләрен сөртеп:
– Озак йөредең, балам, син,
Озак йөредең, балам.

Кайтыр юлга ап-ак томан
Төшәр дә төшәр инде.
Ак томанның аклыклары
Чәчләргә күчәр инде.

*1969*

## Без – җирнеке

Гөлбакчадай матур җирләр.
Ул – минеке.
Бар дөньяда бик бай илләр.
Ул – синеке.
Шартлагычның барысыннан көл
Ясый алырлык микъдары бар.
Ул – синдә дә,
Ул – миндә дә.
Уртак бишек, алтын бишек –
Җир шары бар.
Ул – безнеке.
Шул бишекне тирбәтергә
Хаклы булган аналар бар.
Ул – безнеке.
О, аналар!
Без – җирнеке,
Җир – сезнеке!

*1967*

## Шоңкар моңы

*(Туган авылым нигезендә уйлану)*

Күңел гөлләремне сандугачлар
Ташлап китте инде бүген дә.
Бар дөньяма оран сала-сала,
Шоңкар бөтерелә күгемдә.
Минем кебек ул да ярсу бүген,
Җуйган бугай ул да оясын.
Чит тауларда очып йөргән чакта,
Җил-давыллар ишкән кыясын.
Минем кебек ул да каргый бугай:
– Их, язмышым китсен чәнчелеп,

Туып үскән кыям урынында
Ап-ак ташлар ята чәчелеп!
Туган-үскән илен җуйганнарга
Бу дөньяда тагын ни чара?
Томырылып төшеп, ак ташларны
Чукый-чукый ярсып кычкыра.
...Күңел гөлләремне сандугачлар
Ташлап китте инде бүген дә.
Туып үскән кыя-тавын җуйган
Шоңкар бөтерелә күгемдә.

*1971*

## Гафу сорыйсы бар...

Киткән чакта изүләрне чишеп,
Тальянский гармуннар тартып,
Тамак ертып җырлап йөргән булдык,
Ямьле Тол буйларын яңгыратып.
Тамак ертып җырлап йөргән булдык:
– Каласың, – дип, – сагынып сөйләргә.
Оныткандмын чал философ сыман
Челем тартып яткан Урал-тауга
Сәҗдә кылып башым ияргә.
Чигәләрдән күпме яшьләр акты,
Шушы онытуыма ачынып.
Кайтам инде, кайтам илләремә,
Онытканым өчен җир-суымнан
Гафу сорыйсы бар баш орып.

*1971*

## Иске тальян

Заманында җир җимертеп йөргән
Тальяннардан инде туйганнар.
Иске арыш капчыгына салып,
Чормаларга элеп куйганнар.
Ә өйләрдә фырт баяннар бии,
Аккордеон бии кулларда.
Йөрәкләргә дәртләр өстәп йөргән
Аһ-зар тулы кара елларда
Тальяннар елый...
Чормаларда
Такмазалап елый кичләрен:
– Фырт баяннар сузган җырларыгыз
Без калдырган моңнар ич әле.
Их!..
Гыйшык сүзе сөйләп яшь кызларның
Йөрәк маен күпме сыздырдык,
Утларына салып яндырдык та,
Бозларына салып туңдырдык та –
Кайгыларны җилгә туздырдык.
Күп ирләрне илдән озаттык без,
«Сау кайтыгыз» диеп,
«Без көтәрбез» диеп җырладык.

Кире кайтмасалар, еладык без,
Хатыннарның, бала-чагаларның
Күкрәгенә ятып еладык.
Их!..
Өйләрдә бәйрәм-туйлар гөрли,
Очынып-очынып бии баяннар.
Чормаларда, капчыкларда үкси
Бабамнардан калган тальяннар.
Тормыш җәберенә түзалмыйча
Асылынган бөек җырчыдай.
Чормаларда тыпырчынып сыктый,
Тыңлагызчы, тыңла, кешеләр!
Күрер күзгә алар искедер дә,
Моңы белән алар көчлеләр.
...Бабам моңын капчыкларда күрсәм,
И, сызлый ла, сызлый бу җаннар.
Кемнәрнедер каргап үлә кебек
Көмеш кыңгыраулы тальяннар.

*1968*

## Төшкән җирләребез ак таш безнең...

Төшкән җирең таш булсын.
*Теләк*

Төшкән җирләребез ак таш безнең,
Таш өстендә гөлләр үстердек.
Шатлыклар да безнең шушы җирдә,
Нужасын да шушында күрдек.

Ак ташларга кара ташлар явып,
Очкын чыкты – илләр яндылар.
Ир-егетләр ак мендәргә түгел,
Ак ташларга киселеп аудылар.

Ни төшсә дә, ташлар еламыйлар:
Ташлар да бер аңа, башлар да...
Алар шунда мәңгелеккә калды,
Әверелеп ап-ак ташларга.

Ташка әверелеп калган ирләр
Ташны үбеп ята бүген дә.
Бәйрәмнәр дә безнең таш өстендә,
Яшебез дә шунда түгелә.

*1968*

## Еллар ага...

Чал дулкынын ярларына кага-кага,
Йөрәк аша, күңел аша еллар ага.
Газиз башны салыр идек дәрьяларга,
Шуның өчен килдекмени бу дөньяга?

Биек-биек тупылларда кош сагышы,

Җан өшеткеч ап-ак карлар ояларда.
Буш оялар бәгырьләрне өзсәләр дә,
Елар өчен килмәдек без бу дөньяга.

Күңелемнең кылларына бәрелә-сугыла,
Бозлар сыман еллар ага, еллар ага.
Бәгырьләрне еллар ертып китсәләр дә,
Елар өчен килмәдек без бу дөньяга.

*1969*

## Тол буенда

Төн буенча Тол буенда йөрдек,
Икебезнең иде тулган ай.
Ике йөрәк типте, Тол суының
Дулкыннары кереп тулгандай.

Без ике яр идек... Юкка чыкты
Ике арадагы дулкыннар.
Безне күреп сөенделәр микән,
Ярдан ярга чапты чулкыннар.

Сүз куештык... Ул төн ике ярны
Ак дулкыннар сөеп туймады.
Ак йолдызлар яуды өстебезгә,
Ә ай Толда чумып уйнады.

*1969*

## Хыянәт

«Көтәрсеңме?» – дидем. Аңа кушылып,
Каеннар да башларын иде.
Каеннар да, сөйгән ярым сыман,
Яулык болгап калганнар иде.

Илгә кайттым.
«Көтәм» дигән ярның
Туй шау-шуы килә өеннән.
Яулык болгап калган каеннар да
Әрдәнәгә кисеп өелгән.

*1976*

## Көзге моң

Күңелемә көзләр килде,
Дөньялар сары, сары.
Сары дөньяны агартып,
Эх, яусын иде кары.
Сары сандугачлар кунып
Саргайтты тирәгемне.
Дөнья сарылыгы чәнчи
Сагышлы йөрәгемне.
Учларымны җәеп торам,
Ак кар ява икән дип.
Энҗедәй ак кар дигәнем
Кырказ яше икән бит.

Күзләр белән китсен иде
Дөньямның моңы-зары.
Сары дөньямны агартып,
Эх, яусын иде кары.

*1969*

## Янгынчы монологы

Булдыра алсам, бер янгынчың
Булыр идем синең, Җирем.
Янгыннарны сүндерүгә караганда
Кисәтүе җиңел.
Мин – янгынчы.
Каланчам бар, гади авыл каланчасы –
Биек түгел.
Шуннан күзәтәмен
Авылымның, туган җирнең күген.
Янгын күреп,
«Ут!» хәбәре алсам берәр җирдән,
Алга ыргылырга ат җигелгән.
Җир шары зур.
Кемдер анда шырпы сыза яндырырга.
Хакыбыз юк бу Җир шарын
Янгынчысыз калдырырга.
Кайвакытта
Янгын каплый илләр күген.
Кычкырсам да,
Ишетмиләр тавышымны,
Ишетмиләр!
Каланчам бит биек түгел.
...Булдыра алсам, бер янгынчың
Булыр идем синең, Җирем.
Янгыннарны сүндерүгә караганда
Кисәтүе җиңел.

*1969*

## Аклык алып булмас инде...

Аклык эзләп йөгерсәм дә
Ак каеннарга таба,
Яланнарда да бит хәзер
Каен сарысы ага.
...Йөгереп барсам, йөрәгемә
Сары сагышы тама.

Өзгәләнеп үкси-үкси
Күңелнең сызлавыннан
Сарылсам да каеннарга,
Котыла алмыйм узганымнан.
...Аклык алып булмас инде
Ак каен тузларыннан.

*1969*

## Кояш баеганда

Моңсу гына кояш байый...
Кызыл шәфәкъ
Туасы көн таңы төсле.
Алсу нурлар шунда китеп,
Кайтмый калганнарның каны төсле.

*1968*

## Тормыйсыз ла, картлар...

*Әндәр Батыркаев истәлегенә*

Безнең җилкәләргә саласыз да
Шундый саллы тормыш мирасын,
– Арыдым, балам, черем итим,– диеп,
Юл ташына башыгыз куясыз да...
...Теләсәң ела, теләсәң ешын шунда –
Тормыйсыз ла, картлар, тормыйсыз.
Сездән башка куркынычрак ла,
Дошман белән килсәк күзгә-күз,
Дуслар белән килсәк сүзгә-сүз...
Әгәр сезнең акыл кирәк булса,
Кирәк булса сезнең тәҗрибә,
Йөрәкләрне кысып, гүр ташыгыз кочып
Сагынабыз ла, картлар, сезне без.
Юл ташына башыгыз куясыз да:
– Китә башла, – дисез, – балалар...
Юлда хәлем бетеп туктап калсам,
Гүр-таш арасыннан кубарылып
Кычкырырсыз кебек дөнья ярып:
– Ник туктадың, балам, алга бар!
Сездән алган саллы тормыш йөген
Ят кулларга биргән юк ла без.
Без сөртенгән саен сискәнмәгез,
Арыткандыр тормыш юлларыгыз,
Йоклагыз сез, картлар, йоклагыз.

*1970*

## Учак янында уйлану

Учак яна-яна да ул
Әверелә ич көлгә.
Янып бетәм дип үкенмәм,
Гөлләр үссәләр көлдә.

*1966*

## Мин дөньяның үги улы түгел

Мин дөньяның үги улы түгел,
Анам кебек дөнья үз күрде.
Бер ярдәмсез елак нарасыйны
Колагыннан тартып үстерде.
Башта миңа, назлы анам булып,
Ап-ак күкрәк сөтен имезде.

Ә аннары,
Ачысын да татып карасын дип,
Иренемә әрем тигезде.
Үсә төшкәч, уенчыклар бирде:
– Менә монысы синең нәфрәт, – диде. –
Менә монысы синең мәхәббәт,
Менә монысы синең шатлык булыр,
Ә монысы синең һәлакәт.
Болар синең юанычың, – диде, –
Ватмый-нитми сакларсың аны,
Син шулардан тезеп кара, – диде, –
Тормыш дигән гүзәл бинаны.
Ул бинаны төзү җиңел түгел,
Тешне кысып түзәм өйгәндә.
Кайчагында бинам җимерелә,
Өйдем генә инде дигәндә.
Мәхәббәтем чәлпәрәмә килә,
Нәфрәтем килә зил-зәбәр.
Шунда дөнья йөзен чытып боера:
– Минем улым түгел син, – ди миңа, –
Төзәлмәсәң шуларны әгәр.
...Мин дөньяның үги улы түгел,
Анам кебек күрәм дөньяны.
Һәлакәтне шатлыкларга салып,
Нәфрәтне мәхәббәткә салып,
Төзим әле
Тормыш дигән гүзәл бинаны.

*1971*

## Тай өйрәткәндә

Тай өйрәтә яшь егетләр.
Тач күбеккә баткан тайлар
Авызлыгын чәйнәп дулый...
Аксакаллар: «Шәп ат булырлар!» – дип
Мактап туймый.
Ә малайлар ат-ат уйный...

Өйрәттеләр:
Кем йөк тартыр каерылып,
Кем чабышкы булыр сабантуйда?
Өйрәтелгән яшь тайларның
Тезгеннәрен тотып кулга,
Яшь егетләр тора тирән уйда...
Аксакаллар тора,
Яшь малайлар тора,
Һәм мин торам,
Ат язмышы белән
Ир язмышын уйлап.

*1975*

## Дошманыма

Гаделлекне саклап яшәдек без,
Курыкмыйбыз гадел орыштан.
Көрәшергә чыксаң, шуышып түгел,

Бар буеңа басып чык, дошман.
Билдән алганнарны яратабыз,
Тарткалама куркып син җиңне.
Калтыранма, дуэль мәйданында
Калтыранган Дантес шикелле.
«Куркак җанлы дуска караганда
Батыр дошман булсын»,– диябез.
Мәкер идерә алмас безнең башны –
Батыр җиңсә генә иябез.
Гадел көрәш көткән дошманнар бар,
Мәкер саклап йөргән туганнар...
Горурланам шуңа:
Без бар буйга басып йөрегәндә,
Күкрәк киереп
Йөри алмый әле дошманнар.
Агуларын эчләренә йотып,
Елан кебек, бездән качып-посып,
Җирдә шуышып йөри бит алар.

*1971*

## Иркенлек иңә күк җаныма

Чиклелек, тарлыктан интегеп,
Зиһенем талчыгып кала да,
Мәрхәмәт сораган шикелле
Йотлыгып текәләм галәмгә.
Никадәр иркенлек!
Никадәр
Чикле бит кешелек акылы!
Идеал – йолдызлар җемелди
Миллион чакрымнар аркылы.
Хыяллар очалар, очалар
Шул төпсез чиксезлек ягына.
Шул чакта илаһи киңлектән
Иркенлек иңә күк җаныма.

*1971*

## Берәүгә мәрсия

Харап булды мәрхүм, харап булды...
Чын күңелдән жәллим мин аны.
Китте барды кунак егете күк
Үткәрде дә фани дөньяны.
Инсафлы да кеше иде инде,
Тартмады ул, хәмер эчмәде.
Грамотный кеше иде мәрхүм –
Кантурларда гына эшләде.
Талашмады тормыш юлында ул,
Кеше өчен күлмәк ертмады.
Әгәр җил-бураннар очраса,
Кеше ышыгында атлады.
Алдынгылык яклы кеше иде.
Артта калганнарны сөймәде.
«Мин булышам, туган!» – димәсә дә,
«Булышаек, – диеп, – артталарга!» –
Җыелышларда нотык сөйләде.
Мактаганны, ай-һай, сөя иде,
Кабул итә иде шелтәне.

Мактасалар, авыз ерып торды,
Хурласалар, телен тешләде –
Гөрләп бара иде эшләре.
Шундый кеше дөнья куяр диеп
Башына килмәгәндер һичкемнең.
Узган чакта жәлләп узар өчен
Кабере генә калды мескеннең.

*1971*

## Кеше өчен күлмәк ертма, дисең...

Кеше өчен күлмәк ертма, дисең,
Сакла, дисең, сакла үзеңне...
Беләсеңме:
Күптән инде гүрдә булыр идек,
Тотсак әгәр синең сүзеңне.
Күптән инде гүрдә булыр идек,
Кеше өчен күлмәк ертмасак.
Туганнарга дошман килгән төндә
Тәмле төшләр күреп йокласак.
Йортыбызга килгән кунакларның,
«Хуш киләсез, әйдүк, туганнар!» дип,
Каршысына йөгереп чыкмасак.
Күптән инде гүрдә булыр идек,
Күлмәкләрне ертып ташланмасак
Дуска керер пычак астына,
Дусны буар элмәк астына...
Афәт йөри әле җир йөзендә –
Җәйрәп ята адәмнәр каны.
Кеше өчен күлмәк ертып кына
Саклыйбыз бит әле дөньяны.
Планетада сабан туе түгел,
Җирдә давыл әле, җирдә дау.
Көрәшләрдә күлмәк ертылса да,
Йөрәк әле безнең исән-сау.
Кеше өчен күлмәк ертма, дисең.
Бәхетле син,
Ләкин бәхетеңнән көнләмим.
Тыныч яшә, әгәр тормышыңнан
Кыйммәтрәк булса күлмәгең.

*1971*

## Безгә, татарларга, барыбер

Нам, татарам, все равно,
Что сабантуй, что война.

*Рус халык әйтеме*

Безгә, татарларга, барыбер, туган,
Сабантуймы анда, сугышмы...
Кылыч тотып яуга барабызмы,
Сабантуйга китеп барабызмы –
Безнең көрәш саклау өчен булса,
Яклау өчен булса тормышны –

Безгә, татарларга, барыбер...
Йортыбызга кунак булып килсәң,
Кылыч белән күзгә юлыкма –
Татарларның андый кунакларга
Яман икәнлеген онытма.
Кылычыңны, туган, куеп кер,
«Исәнмесез» диеп сәлам бир.
Телең нинди синең, илең нинди –
Безгә, татарларга, барыбер.
Түребезгә
Аяк бөкләп утыр татарча.
«Такта чәем, ачык чыраем» дип,
Татар тастымалын сыга-сыга
Чәй эчәрбез, туган, татарча.
...Безгә, татарларга, барыбер, туган,
Сабантуймы анда, сугышмы.
Мәйданнарда батыр калабызмы,
Сугышларда ятып калабызмы,
Исән-имин булса туган җир,
Безгә, татарларга, барыбер...

*1971*

## Җиңнәреңне сызган...

Тормыш, туган, сабан туе түгел,
Җиңел бирелә димә син аны.
Рәт чыгармы бу бәндәдән диеп,
Кырык тапкыр мине сынады.
«Сөя белә микән»,– диде бугай –
Сөйгән ярдан аерып карады.
Көче бармы икән торырга дип,
Аяк чалып егып карады,
«Яна микән, бата микән», – диеп,
Утка, суга салып карады...
Төсләр бирде миңа, янәсе, бу
Аерамы акны-караны.
Чибәр кызлар хәмер-шәраб белән
Әллә ничә алдап карады –
Алданмадык!
Әгәр бәреп екса,
Сикереп тордык, хушсыз ятмадык,
Утка салса, янмый кире чыктык,
Суга салса, суда батмадык –
Вөҗдан белән ап-ак мәхәббәтне
Йөрәкләргә кысып сакладык;
Көрәшләрдә күкрәк яраланса,
Ярабызны көлмәк каплады.
...Тормыш, туган, сабан туе түгел,
Җиңел бирелә димә син аны.
Җиңнәреңне сызган, чык көрәшкә,
Синең алда тормыш сынавы.

*1970*

## Киләчәкне даулау авыр җирдә

Киләчәкне даулау авыр җирдә.
Иртәгесе туар көн өчен
Көрәшләрдә ялгыз калганым бар,
Учка кысып сынык кылычым.
«Иртәгесен ишәк кайгырган» дип
Йөрүчеләр җирдә азмы соң?
Дуслар ташлап китә кулын селтәп,
Теш ыржайтып көлә язмышым.
Сынык кылыч, китек күңел белән
Тагын ташланасың
Тормыш киләчәген сакларга.
Бу дөньяның берәр сволоче
Йөзгә пычрак орган чакларда,
Башны ташка орып елар идем,
Ирлегемнән оят еларга.
Яшьне йотып бары елмаясың,
Күзең төбәп туар елларга.

*1970*

## Ташландык үлчәвеч

Әллә кайда түгел,
Үз илемдә,
Күчтәнтидә, ындыр артында,
Бер ташландык үлчәвечкә юлыгып,
Уйга калдым гомер хакында.
Мин таныдым аны:
Гамәлендә чакта
Ул үлчәде
Бик күп авырлыкның микъдарын.
Шул чакларын искә төшергәндәй
Утыра ул хәзер тын калып.
Тыныч кына узып китә алмассыз,
Күчтәнтидә аны күрсәгез.
Шулай тып-тын сыгылып елый төсле
Гомер буе авырлыкны үлчәп
Эштән чыккан
Иске үлчәвеч.

*1981*

## Илле яшем

*Фәһимә апага*

Яшь вакытым – алсу җәем узды инде,
Гомеремнең алтын көзе килде инде.
Күңелемә көз сарысы иңде инде,
Миңа хәзер илле инде, илле инде.

Утым сүнде, гомерем узды дип үкенмим,
Күңелемдә уйный әле утлы яшен.
Күкрәгемә күкрәү булып, җил-давыллап
Килеп җитте илле яшем, илле яшем.

Яшьлек китә, картлык килә, дип сөйлиләр,
Адәмнәрнең карамыйча кемлегенә.
Бер уйласаң, яшьлек әле килде генә –
Миңа әле илле генә, илле генә.

*1981*

## Акбүз ат

*(Балачак хатирәсе)*

Акбүз атның аякларын бәйләп,
Башын бәйләп җиргә салдылар.
Салдылар да ялларыннан сыйпап,
Иркәләгән булып... чалдылар.
«Аткаемны нишләттегез?!» – диеп,
Ыргып-йөгереп килдем, түзмәдем.
...Миңа томырылып ачык калды
Малкаемның яшьле күзләре.
Ул чагында бер нарасый идем,
Ни гөнаһым булды, изге зат.
Гомерем буе шулай томырылып
Ник карыйсың миңа, Акбүз ат.

*1968*

## Олы сәфәр чыгып барасыз

Ләйлә-Мәҗнүн кебек җитәкләшеп
Юнәлдегез кая таба сез?
Беләм, беләм: бәхетегезне эзләп,
Зур сәфәргә чыгып барасыз.

Җирдә хәзер әле кәккүк ае,
Яланнарда кәккүк моңлана.
Кайгыларны ялгыз кәккүк күрсәң,
Пар аккоштай яшәп дөньяда,
Ак күңелле алмаш үстерегез.
Сикәлтәсе булыр, упкыннары...
Сөртенмәгез берүк юлларда.
Ташка бәрелеп йөзләр канаса да,
Кирәк түгел үксеп еларга.
Яшьне йотып елмаюлар тиеш,
Күзең төбәп туар елларга.
Ләйлә-Мәҗнүн кебек җитәкләшеп
Юнәлдегез кая таба сез?
Беләм, беләм:
Бәхетегезне эзләп,
Олы сәфәр чыгып барасыз.

*1972*

## Бишекләр тирбәлә күңлемдә

Дәү булып үсәсе җыр тулы
Бишекләр тирбәлә күңлемдә...
Шул җырлар язмышын кайгыртам,
Кар ява күгемдә бүген дә.
Бишектә тибрәлгән җырларым –
Бабамнар җырының оныгы...

Йөзендә елмаю сирәк шул –
Шуңа да җаныма тынгы юк.
Сызлаган йөрәкне телгәләп,
Чор аша чичәннәр эндәшә:
«Кем анда өнемне ишетә?
Җырымны хөр яшәт, мең яшәт!»
Бабамнар моңының онытгын
Бишектә тибрәтәм күңлемдә...
Шул җырлар язмышын кайгыртам,
Кар ява күгемдә бүген дә.

*1969*

## Песнәк

Зәмһәрир кыш. Үз бүлмәмдә утырам,
Тәмен табып җылы өемнең.
Форточкадан песнәк очып кергәч,
Сабый бала кебек сөендем.

Кабаланып тәрәзәмне яптым,
Тышта салкын – суык кермәсен.
Бу кошчык та гел җәннәттә яшәр –
Чыгып кына китә күрмәсен!

Һәм тагын да ләззәтемә чумып,
Джаз тыңлыйм, дәртле җыр тыңлыйм.
...Тик шул вакыт тынычлыгым бозып
Ярсып-ярсып песнәк чыркылдый.

Канатлары белән һава кисеп,
Яшен ташы булып атыла.
Сары каурыйлары каерылып
Тузып-тузып кала артыннан.

Өзгәләнеп стенаны чукый,
Фикусларга кунып ярсына!
Алты квадратлы фатирымны
Песнәк булып, песнәк тарсына.

Иркенлеккә чыгарыйм дип аны,
Ишек ачмак булдым – соңардым...
Ядрә сыман килеп, тәрәзәмнең
Пыяласына килеп сыланды.

Кан таплары калды пыялада –
Песнәк гомерен саклый алмадым.
Киңлекләргә ыргылучы җанны
Тәрәз пыяласы алдады...

Канлы тәрәз аша тышка карыйм,
Чиксезлеккә оча хыялым.
Безгә дә бит шундый җан биргәнсең,
Андый язмыш бирмә, Ходаем.

*1968*

## Җир-ана

Куанычлар көткән балаларның
Сындырмаска диеп теләгән,
Бала-чага тулы карусельдәй
Әйләнә ул кояш тирәли.

Шунда әгәр берсе арып китсә,
Мәңгелеккә төбәп карашын:
«Бераз гына черем итеп ал», – дип,
Куенына ала баласын.

*1971*

## Әкият баласы мин

Балачакта Шомбайлар һәм
Хуҗалар белән үстем.
Алпамшадай, Гөлнәзектәй
Батырлар күреп үстем.
Мин әкият баласымын,
Гөлчәчәктән туганмын,
Салам-Торхан, Алыпларның
Булам кече туганы.
Аждаһа һәм диюләрне,
Пәриләрне җиңгәндә,
Абыйларым кайтмый калган
Ерак-ерак илләрдән.
Ә бу таулар Алыпларның
Чабата каккан төше.
Кызарып чыккан кояш та
Аларның каны төсе.
Мин дә абыйларым сыман
Бер янып калыйм әле.
Алардан калган тауларга
Сарайлар салыйм әле...

*1967*

## Сагынылды

Сагынылды туган-үскән илем –
Төшләремә кереп йөдәтә:
Кулларымнан алып, балачагым
Таныш сукмаклардан йөгертә.
Сөенешеп тора каеннарым,
Билләремнән ала кочаклап.
«Абый кайтты, абый кайтты», – диеп
Кул чәбәкләп тора усаклар.
«Улым кайткан», – диеп, олпат нарат,
Хозур чыршы килеп күрешә.
Барып чыгам чишмә ярларына –
Чишмәләрем сөенеп көлешә.
Симфониясен башлый карурманым,
Ничек түзим аңа кушылмый.
Чигәләргә иелеп, арышларым:
«Рәшит, ашык», – диеп пышылдый.
Сагынылды туган-үскән илем –
Төшләремә кереп йөдәтә:

Кулларымнан алып, балачагым
Таныш сукмаклардан йөгертә.

*1969*

## Бүген тагын...

Бүген тагын ятлар белән киттең,
Шыгыр-шыгыр итеп ак карны.
Кара төнгә сөйләп кайттым әле
Күңелемнән ташкан моң-зарны.

Моңнарымны уйсу җилләрем дә
Дус этләрем генә ишетте...
Бүген төнен этләр улагандыр,
Тырный-тырный синең ишекне.

Ә иртәгә, башын ора-ора,
Өй түреңдә каенның еласа,
Гаҗәпләнмә...
Кичә ак каеныңа
Башым салган идем ләбаса.

*1969*

## Татар җыры

Без түгел бит, җыр моңая:
«Яңгыр микән, кар микән?
Җырласам, елыйсым килә,
Әллә гомерем аз микән?»
Без түгел бит, җыр моңая:
«Кайгым күкләргә ашкан...»
Без түгел бит, без түгел бит –
«Кош баласы адашкан».
...Галәмгә иңрәп, татарның
Җыры мәрхәмәт сорый,
Безнең елап яшьләр бетте,
Ул һаман еламсырый.

*1970*

## Кайттым бит...

Кайттым бит, кайттым яныңа,
Кайттым бит, әни-җаным.
Синең җылы куышыңны
Сагынып кайттым тагын.

Каршыма чыктың йөгереп,
Ишегең ачык калды.
«Кер, балам, кер, җылын», – диеп,
Йөрәгең ачып салдың.

...Йөрәк ачык, бәгырь ачык,
Күңел ачык иңенә.
Ачык йөрәкләр күп алар,
Җылытканы син генә,
Дөньясында бер генә.

*1971*

## Юл буенда үскән каен

Каезланып язган исемнәрдән
Кәүсәсе дә аның чуп-чуар.
Ботакларын аның ат кауларга
Сындыргалый бары юлчылар.

*1971*

## Тастымал

Сабан туйларында ат ялында
Җилфер-җилфер йөргән, ихтимал.
Хәзер инде исерек, бай табында
Сеаләгәй сөртә инде тастымал.

*1975*

## Балалар паркында

Балаларның ял паркына кереп,
Тема эзләп йөрим кайчакта.
Балалар да йөрми, тема да юк –
Бик күңелсез инде шул чакта.
«Шүрәлеләр» тора уйга калып,
«Убыр карчык» баткан кайгыга.
Балачагын сагынып, бер чал карт һәм
Бер чал карчык йөри җай гына.
Почмак саен төркем-төркем булып
Салметдиннәр план коралар.
Ял итәргә чыккан фырт туташлар
Агач саен туктап бурзайларының
«Пес» иткәнен көтеп торалар.
Могҗизалар тулы шул бакчада.
Их! Бер уйнар идем,
Чыр-чулары белән
Үткән инде, үткән балачак.
Әнә!
Эскәмиянең аркасына утырып,
Бер пар үбешә.
...Димәк, әле тема булачак.

*1981*

## Биекләргә кыен давылда

Давылдагы фаҗигане күреп,
Сыктамыйча калдым тыелып:
Чатнап сынган чакта карт карагай,
Таллар калды җиргә сыгылып.

Дөньяда бу соңгы давыл булмас,
Зилзиләләр килер тагын да.
Баш ия алган иелер дә калыр,
Биекләргә кыен давылда.

*1981*

## Бик кайтасы килә...

Үсмер чакта, егет булабыз дип,
Әй, тырыштык инде, ах ордык:
Керпе энәседәй чәчебезне
Сулап-тарап артка яткырып.
Зур буласы килеп, өй артында
Качып-посып махра көйрәттек.
Егетләрнең теңкәсенә тидек:
«Кызлар белән
Сөйләшергә безне өйрәт», – дип.
Анысына, шөкер, тиз төшендек,
Сөю-сәгадәткә
Тиенмәдек түгел, тиендек...
Еллар үтте инде, яшьлек китте,
Бабай киеменә киендек.
...Хәзер инде онык чәчен тарый.
Ул-бу кормасын дип,
Көнен-төнен торамын сакта.
Ә үземнең бик кайтасым килә
Керпе чәчле, махралы чакка.

*1981*

## Бир әле, җил, кодрәтеңне

Бир әле, җил, кодрәтеңне,
Бер синең кебек дулап
Узасы бар җир буйлап!
Тузгытасы бар дөньяның
Сәләмә, черекләрен.
Җилләтәсе бар миләрен
Рухи исерекләрнең.
Айкап чыгасы бар җанын,
Бәгырен мещаннарның.
Акшар сибәсе күңеленә
Сасык, кара җаннарның.
Җилкәнен киерәсе бар
Бриз көткән корабның.
Дөрләтәсе бар күңлендә
«Күзларын» битарафның.
Бир әле, җил, кодрәтеңне,
Бер синең кебек дулап
Узасы бар җир буйлап.

*1981*

## Без авылда үскән егетләр ич...

Без авылда үскән егетләр ич,
Кояш улы, кырлар малае.
Моңлы булсак, бер дә гаҗәпләнмә –
Моңын биргән сабан тургае.

Без авылда үскән егетләр ич,
Җаныбызга
Моңы сеңеп калган тальянның.

Кулыбызга арыш исе сеңгән,
Йөзебезгә –
Кызыллыгы алсу таңнарның.

Без авылда үскән егетләр ич,
Күңелебездә
Аклыклары ак каеннарның.
Уйчан булсак, бер дә гаҗәпләнмә,
Безнең күздә
Боеклыгы төнбоекларның.
Без авылда үскән егетләр ич,
Гаҗәпләнмә,
Булып китсә ярсу, шашулар.
Ярсулыгын биргән чаптар атлар,
Шашкынлыгын – язгы ташулар.

Без авылда үскән егетләр ич,
Безнең башка, үзгә горурлык.
Гомеркәебезнең һәр мизгеле
Җырын, моңын, телен җуйганнарның
Бөтен гомеренә торырлык.

*1981*

## Вакыт юк

Дөнья – куласа:
Әйләнә дә бер баса.

*Мәкаль*

Дөнья куып байтак йөгерәбез –
Вак-төякләр өчен вакыт юк.
Читкә ташлап тормыш мазаларын,
Дуслар белән
Гөрләп утырасы килә – вакыт юк.
Хыялларга чумып, күккә карап
Ятасылар килә: вакыт юк.
Авыру дуслар савыгалар микән –
Барып хәл белергә вакыт юк.
Дөнья куып тыз-быз чабышабыз –
Арка кашырга да вакыт юк.
...Бигрәк эш кешесе булып киттек,
Гөрләп кенә бара эшебез.
Кайгы да юк кебек,
Шатлык та юк,
Куласада чапкан тиен кебек,
Яшибез да шулай яшибез.
Куласада чапкан тиен кебек
Зырлап әйләнәбез, әллә-лә!
Куласа әйләнгәнгә без чабабыз;
Без чабабыз – куласа әйләнә.
Куласада чапкан тиен кебек
Әйләнәбез: дөнья – куласа.
Күпме әйләнсәң дә,
Тиене дә һаман шул ук тиен,
Куласа да шул ук куласа.
Әйләнүләр күпкә китә бугай:

Кайчагында
Аңгы-миңге килә башыбыз.
Тормыш мәгънәләрен шул куласа
Баскач кына аңлый башлыйбыз.
Бигрәк эш кешесе булып киттек –
Вак-төякләр өчен вакыт юк.
Нигә юк?
...Шуны уйларга да вакыт юк.

*1985*

## Тургай үлеме

*Сәрия апа Кәбирова истәлегенә*

Гашыйк җаннар күккә томырыла,
Гашыйк җаннар алар гел шулай:
Соңгы минутында күккә ашып,
Илен, җирен мактап бер җырлый да
Йөрәге ярылып үлә, ди, тургай.

Бер тургае идең син дөньяның,
Туялмадың сөеп җиреңне.
Гомерең дә тургай гомере булды,
Үлемең дә тургай үлеме.

*1982*

## Карнавал

Бүген залда зур карнавал бара,
Бүген залда гөрли маскарад.
Тик мин генә чыгып бии алмыйм:
Мин жюрида – утырам карап.
Арысланнар куян белән бии,
Ә кәҗәләр сырыша бүрегә.
Яшь бер тавык төлке муенына
Үрелә дә һаман үрелә.
Йөнтәс маймыл маймыллыгын итә –
Йөренә дә һаман йөренә.
Алай итеп, болай итеп карыйм,
Таный алмыйм, каһәр төшкере.
Арысланы кем дә, куяны кем,
Ә кем кигән маймыл битлеге.
...Тормыш та бит безнең карнавалдай,
Адәмнәрнең
Чын йөзе бар һәм дә битлеге.
Арысланы кем дә, куяны кем,
Ә кем кигән маймыл битлеге –
Танып булмый, каһәр төшкере.

*1985*

## Сөю уты

*(Җыр)*

Сагынганда яшьлегемне,
Тулган айларга карыйм.
Ай булып калды күңелемдә

Яшьлектә сөйгән ярым.

Сагынганда яшьлегемне,
Ай-йолдызларга карыйм.
Күп йолдызлар арасыннан
Без яратканын таныйм.

Сөю уты сүнми әле,
Өмет һаман өзелми.
Ай булып балкый күгемдә,
Йолдыз булып җемелди.

*1984*

## Чакыр мине биергә*

*(Җыр)*

Күз аткалап тормале син, егет,
Кил каршыма елмаеп һәм көлеп.
Чакыр инде мине,
Чакыр инде мине,
Чакыр инде мине биергә бер килеп.

Кушымта:

Һәркем эзли җирдә үз ярын,
Һәркем таба җирдә үз парын.
Мин генә шул, мин генә ялгыз.

Синең өчен генә күңел җылым,
Синең кулың көтә минем кулым.
Биеп узыйк бергә,
Биеп узыйк бергә,
Биеп узыйк бергә гомер юлын.

Кушымта.

*1987*

## Һай, гомерләр...

*(Җыр)*

Һаваларга баксам – кошлар китә,
Җиргә баксам – алтын көз инде.
Бакчалардан алма аваз сала:
– Әй, мосафир, авыз ит мине.

Кушымта:

Гомер уты яна күңелләрдә,
Балкып-балкып ала куз-күмерләр.
Һай, гомерләр, һай, гомерләр.

Алмагачтан алтын алма төште,
Соңгы яфрак төшәр агачтан.
Бу гомерләр чиксез яну булды,

Яну гына булды тоташтан.

Кушымта.

Язлар булсын өчен күзләр кирәк,
Кышлар кирәк язлар булсынга.
Дөньялыкның алтын җәе өчен
Мең рәхмәтле, тормыш, мин сиңа.

Кушымта.

*1994*

## Барда такмаклары

Бардаларга кил, дидең дә,
Килсәң, китәрбез, дидең.
Сахрадагы кошлар кебек
Гомер итәрбез, дидең.

Барган идем, әйттең миңа:
– Шунда береккән күңел.
Күңел береккән илемне
Ташлап китәрлек түгел.

Барган идем Бардаларга
Сине генә алмага,
Язган икән шул илләрдә
Гомерлеккә калмага.

Бардаларның күңелендә
Матур хыял, матур уй.
Бардаларга бармас идем,
Ярты җаным шунда кый.

Сөен күңел, җырла күңел,
Ашкын күңел, ян күңел.
Бардаларда узган гомерем
Заяга узган түгел.

*1995*

## Яшьлек язы*

*(Җыр)*

Язгы бозлар киткән чагында
Яшьләр чыга Тол буйларына.
Күңел күккә аша,
Йөрәктән моң таша –
Җыр агыла туган ягыма.

Тол сулары кага ярларга,
Ак болытлар уйный тауларда.
Синнән, Урал тавым,
Илһам алган чагым
Яңа биеклекләр яуларга.

Сандугачлы язгы таңнарда
Җырлый-җырлый чыгам тауларга.
Җырлы яшьлек язы,
Бәхетле яз шавы
Яңгырап китсен туар елларга.

*1988*

## Җиләкле аланнар

*Мәсгут Имашевка*

Җиләк айларында тугангамы,
Күңел аланнарың җиләкле.
Шул аланнар һәрчак дәшеп тора,
Ымсындырып тора йөрәкне:
«Җир җиләге бирим микән сиңа,
Каен җиләкләре кирәкме?»
...Алан читләрендә кызыл балан –
«Балан бирәм» дими нишләптер.

Җәйләр буе җиләк җыйды халык.
Утырып калды көзен
Канлы яра төсле баланнар.
Алар дәшә хәзер: «Баланыма
Кагылмагыз инде, оланнар».

*1993*

## Татарстан гимны

Юкка гынамыни, Татарстан,
Бәйсез дәүләт даулап ярсыдың.
Барс булып сикер киләчәккә,
Бәйсез булыр көнең бар синең.

Чит илләрдә солтан булсам да мин,
Олтан булып сиңа кайтырмын.
Яшә, туган җирем Татарстан,
Ышанычы булып татарның.

Җир-суларың – җәннәт, туфракларың
Икмәкләргә ягып ашарлык.
Синдә үткән газиз гомеремнең
Һәр минутын санап яшәрлек.

Кагу-сугу күреп читтә йөрдек,
Ачыларын күрдек заманның.
Бәхетебез шушы җирдә безнең –
Каны тамган җирдә бабамның.

Киләчәгең якты булыр синең,
Өмет белән ата һәрбер таң.
Хөр мәмләкәт, бәйсез дәүләт булып
Яшә, яшьнә, күкрә, Татарстан!

*1990*

## Бәхетсез ир

Димләделәр аны, мөмкин диеп
Бер кашык су белән йотарга.
Капты-йотты. Хәзер хәле мөшкел,
Урын эзләп йөри косарга.

*2000*

## Барда түбәтәйләре*

*(Җыр)*

Барда кызы, кич утырып,
Кемгә түбәтәй чигә?
Гашыйк булдым Бардада шул
Түбәтәй чигүчегә.

Кушымта:

Эх, Барда түбәтәе,
Бик килешә түгелме?
Биетә дә, җырлата да,
Ярсыта да күңелне.
Эх, Барда түбәтәе,
Бик килешә, карале!
Бардаларда кияү булып
Йөриселәр бар әле.

Сабантуйда Барда кызы
Түбәтәй бүләк итте.
Түбәтәен бүләк итте –
Йөрәгемне җилкетте.

Кушымта.

Кызлар чиккән түбәтәйнең
Кызыл чәчәк өлгесе.
Кызыл чәчәк өлгесе ул –
Вәгъдәләшү билгесе.

Кушымта.

*1999*

## Көрәш мәйданында

Сабан туйларына килеп керсәм,
Нигә, йөрәк,
Ярсый-ярсый шулай янасың?
Көрәш мәйданына атылып чыгып,
Киләмени батыр каласың?
Еллар буе пыскып йөрүләрдән
Ялыктың шул, ахры, ялыктың.
Ян син, йөрәк:
Без бит оныклары
Алыплары булган халыкның.
Без бит көрәшчеләр токымыннан,
Шул токымның
Дәвамнары инде ләбаса.
Ян син, йөрәк,
Чакыр мәйданнарга!
Без бит әле

Ясалмаган кара калайдан.
Сабантуйда җиңү серләренә
Бала чактан
Төшендергән безне агайлар,
Көрәш-бәйгеләрне башлаттырып
Безнең ише малай-шалайдан.
Бүген алар мәйдан читләрендә
Серләшәләр, гәпләр коралар.
Әйтерсең лә
Алар күзе белән
Көрәшләрдә ятып калган ирләр
Кайтып безгә карап торалар.
Уйланалар:
«Оныкларыбызның
Сыек түгел микән билләре?
Дәвам итәрлекме безнең данны,
Саклый алырлыкмы илләрен?
Беләләрме көрәш кануннарын,
Ысулларын
Егылуның, селтәп салуның...
Беләләрме серен,
Дошман аяк чалса,
Егылмыйча басып калуның?»
Кайгырмагыз әле, әй, агайлар,
Оныкларыгызның
Көрәш уты дөрли җанында.
Сезнең дәвам булып чыктык ич без
Сабан туе мәйданнарына.
Беләбез ич:
Аяк чалганнарны
Кабат мәйданнарга
Чыгалмаслык итү кирәген.
Егылырга туры килгәндә дә,
Йөзең белән төшү кирәген.
Беләбез ич! Үзегез өйрәттегез:
«Бил бирмәскә,
Аякларны
Җирдән аермаска! – дидегез. –
Туган туфрагыннан аерылганнар
Чалкан барып төшә», – дидегез.
Кайгырмагыз әле, әй, агайлар,
Чалкан төшү булмас,
Чыксак та без нинди батырга.
Егылырга туры килгәндә дә,
Капланырбыз бары йөзләр белән
Туган җирне
Мәңге-мәңге үбеп ятарга.
...Әйдә, йөрәк, чыгыйк көрәшләргә!
Пыскып янулардан
Ялыктың шул, ахры, ялыктың.
Китерегез сөлге!
Мәйданнарга чыга оныклары
Алыплары булган халыкның.

## Ат чабышында

Яшь егетләр сабан туйларыннан
Ат уйнатып чыгып киттеләр.
Күңелемдә яткан тулпарларга
Камчы белән сызып үттеләр.
Камчы белән сызып үтте алар,
Сискәндереп
Җанымдагы шашкын җегәрне.
Тулпарларым, куш аякка басып,
Дөнья ярып кешнәп җибәрде.
Тулпарлары кешнәп тормый икән,
Егетләрнең
Бу җиһанда нигә кирәге?!
Кешнәгезче, кешнә, тулпарларым,
Аяк өсте йоклап йөргәннәрнең
Куркуыннан
Ярылыплар китсен йөрәге.
Кешнәгезче, бәйгеләргә чакырып,
Яңгыратып җирем-күгемне.
Сезнең белән очып кына узыйк,
Томырылып узыйк гомерне,
Киләчәккә таба томырылыйк,
Давылларга, җилләргә каршы!
Шул юлларда нәрсә күрсә күрер
Ир егеткәй белән ат башы.
Ерак юлда ниләр булмас дисең,
Аргамагым, бәлки, абыныр.
Шулай булса, әйдә, була торсын –
Башы булса, аты табылыр.
Үзем егылып калсам,
Мәйданнарга
Атым кайтыр әле барыбер.
Кайгырмыйбыз.
Нигә кайгырырга?!
Газиз башлар
Бәлаләргә әгәр тарыса,
Юлда аргамагым арыса...
Шул сәбәпле башка чаптарлардан
Бераз гына артта калынса,
Кайгырмыйбыз.
Сабантуйда аны
Гаеп итеш булмый лабаса.
...Шундый безнең халык:
Бәйгеләрдә
Артта калганнардан көлмәде.
Бүләгенең
Иң затлысын җиңүчегә бирсә,
Иң газизен
Артта калганнарга бәйләде.
Бәйгеләргә, ярышларга чыксаң,
Күңелеңдә янса
Иң беренче килү теләге,
Җиңәсеңме, артта каласыңмы,
Халкыбызның һәрчак әзер аның
Сиңа дигән газиз бүләге.

Тулпарларым,
Кешнәгезче, кешнә,
Яңгыратып җирем-күгемне.
Сезнең белән очып кына узыйк,
Томырылып узыйк гомерне.

## Капчык белән сугыш

Сугыш-талашларны җенем сөйми.
Тик ни гаҗәп,
Сабантуйда
Капчык сугышы күреп шатландым.
Түзә алмадым,
Җиңне сызгандым да
Агач атка менеп атландым.
Хатын йөри янда тыз-быз килеп:
– Костюмыңны юкка буяма, – дип, –
Юкка бетермә, – дип, – көчеңне!
– Соң бит, хатын,
Мин дә үз гомеремдә
Бер мәртәбә
Сугышырга тиеш ич инде! –
Дидем дә мин,
Башта баҗаемны,
Аннан
Бер зур начальникны
Гөпелдәтеп сугып төшердем.
Әй, сөенәм үзем,
Гомере булмаганны,
«Маладис» дип, хатын сөенә.
Гөнаһ шомлык,
Шулчак күрше егет
Шундый бирде колак төбемә –
Мин капландым пычкы чүбенә.
Их!
Кайгырмале, хатын, егылды дип
Коелмасын әле сөмсерең.
Һәр егылган саен юатучым,
Көч бирүчем инде син минем –
Кайгырмале!
Гадел сугыш ич бу!
Күрше егетенә рәхмәт.
Их!
Рәхәт бит, рәхәт сабантуйда,
Пычкы чүпләрендә ауный-ауный,
Көлеп ятуы да бер рәхәт.
...Көлеп калыйк әле сабантуйда,
Бәгърebeзгә
Кайгы-хәсрәт тулмаганмыни?
Туган туфракларын тырный-тырный
Үксегәннәр булмаганмыни?
Дөньяда бит сабан туе түгел,
Гадел түгел әле орыш.
Капчык белән генә сугышмыйлар –
Дөнья тулы үлеш-кырылыш.
Капчык белән түгел,
Пычак белән

Башыбызга безнең җитәргә,
Чатлар саен кара җаннар тора
Үтереп, талап, кыйнап китәргә.
Дөньяда гел сабан туе түгел,
Бар әле, бар җирдә кан коеш.
Залимнәргә каршы тору өчен
Безнең кулда
Айбалталар булырга тиеш.
...Дөнья сабантуйга әзерләнсен,
Сабантуйлар чыңы
Язгы яшен булып яшнәсен.
Тукталсыннар җирдә чын сугышлар.
Тик яшәсен бары,
Капчык белән сугыш яшәсен!

## Капчык киеп йөгереш

Дөнья куып байтак йөгердек без –
Йөгерүләр безнең ярыйсы.
Әллә шуңа инде
Сабан туйларында
Килә минем
Капчык киеп йөгереп карыйсы.
Йөгерешкә чыкмый ничек түзсен
Бәйгеләргә ашкынган күңел.
Бер уйласаң,
Капчык киеп йөгерүләр дә бит
Безнең өчен яңалык түгел.
Булды тышаусызлар белән бергә
Капчык киеп йөгергән чаклар –
Барыбер чаптык.
Түзмәделәр безгә,
Өзгәләнеп юлда чәчелеп калды
Тышау, богау, чылбыр, капчыклар.
Тышау кырып, аяк канга батты.
Тешне кысып түздек,
Әрнесә дә безнең яралар.
Максатларга таба йөгердек без,
Калышмадык барыбер алардан.
Гомер буе шулай йөгерәбез...
Без дөньяны,
Әллә дөнья безне куалый?
Иркен генә йөгерер идек тә бит,
Кайчак тормыш
Тышаулый шул әле, тышаулый.
Тышаулыйлар безне бюрократлар,
Тормыш ваклыклары тышаулый,
Тышау сала безгә битарафлык,
Көнчелекләр безне тышаулый.
...Ирләр хатыннарын,
Ә хатыннар
Ирләрен дә кайчак «тышаулый».
Абынулар була, сөртенүләр –
Ап-ак йөзләр бетә каралып.
Аяклары азат булганнар да

Егылалар кайчак,
Үз-үзенең
Ыштан балагына уралып.
Абынулар, сөртенүләр булыр –
Таралып ятмыйк, торыйк-йөгерик.
Тормыш нинди капчык кигерсә дә,
Максатларга таба йөгерик без,
Идеалларга таба йөгерик!

## Чүлмәк сугу

Сабантуйда йөрәк ярсый минем,
Килә кайчак
Мәйданнарга сикереп чыгасым,
Мәйданнарга чыгып, җиң сызганып
Ярсый-ярсый чүлмәк сугасым.
Барып басам.
Тоттыралар гөрзи.
Чытырдатып күзне бәйлиләр:
– «Сукыр килеш» кенә тап чүлмәкне,
«Сукыр килеш» кенә бәр, – диләр.
Ник тапмаска безгә?
Беләбез ич,
Күңел күзе белән
Эзләү серен күптән беләбез.
Ялган, мәкер күзне каплаганда,
Кыйблабызны һаман югалтмыйча
Килгәнбез бит әле, килгәнбез.
Булган заман:
Дошман бабамнарның
Күзен бәйләп гөрзи тоттырган.
– Сук чүлмәген! – дигән,
Ә ул җирдә
Бабамнарның дуслары торган.
Көлгән дошман, каһкаһәләп көлгән,
Җан-дусларны
Кызык итмәк булган – оттырган.
Уйлап торган да ул, башын кашып,
Күзен бәйләүчегә
Шундый итеп китереп орган:
Чәлпәрәмә килгән империясе,
Патшалыгы киткән чәнчелеп.
Ярчыклары ята әнә Җир шарында,
Чүлмәк ватыгыдай чәчелеп.
Дусларыбыз безнең дөнья тулы,
Тик юк түгел
Кара эчле дошманнарыбыз.
Шуның ишеләрне кыйратырга
Гөрзиләрне алыйк әле без.
Явызларны, кара эчлеләрне,
Ялган чәчеп йөргән һәркемне
Сугып йөрик әле илләр буйлап,
Сабантуйда
Чүлмәк ватып йөргән шикелле!

## Туры баганага менү

Биеклеккә, күккә ашкынулар
Безнең җанда-канда, күрәсең;
Сабан туйларына килеп керсәм,
Баганага килә менәсем,
Бәйрәмнәрнең матурлыкларын
Биеклектән килә күрәсем.
Бу ашкыну безнең төптән килә,
Төптән килә, төптән – халыктан.
Бабаларым тарих чоңгылыннан
Шундый шома
Баганалар буйлап калыккан.
Кара чорның кара елларында
Хөрлек, яктылыкка зарыккан
Бабаларым өскә тырмашканнар,
Котылу өчен тарлык, коллыктан.
Җан ачысы белән тырмашканнар...
Булган кайчак
Хәлдән таеп тынып торганы.
Кычкырганнар шунда залим затлар:
– Бетте, татар, бетте дәрманың!
Каргылдаган шулай козгын булып
Замананың
Ильминский, Каратуннары.
Каян белсен алар бабамнарның
Көч-хәл генә җыеп торганын?
Сер бирмәгән бабам,
Биеклеккә
Һаман менү ягын караган.
Курсавилар, Мәрҗаниләр белән,
Тукайлары белән яңадан
Һаман күккә ашкан,
Яраланып кулы канаган,
Кайнар каны аккан ярадан.
Канга баткан татар тастымалын
Күк астына
Байрак итеп барыбер кадаган.
...Биеклеккә, күккә ашкынулар
Бабамнардан
Мирас булып калган, күрәсең:
Сабан туйларына килеп керсәм,
Баганага килә менәсем;
Шуннан торып:
– Без бар!
Без яшибез! – диеп,
Бар дөньяга сәлам бирәсем.

## Авыш баганага менү

Сабантуйда йөрәк ярсый минем,
Килә тагын нидер эшләсе.

Әллә инде,
Авыш баганага йөгереп менеп,
Әтәчләрен алып төшәсе.
Әтәч алу безгә берни түгел,
Әтәч алу безгә чүп кенә.
Менгән чакта тигезлекне саклап,
Саграк булу кирәк чүт кенә.
Саграк булу кирәк...
...Тормышта да
Һәрберебез өчен
Куелган ич шундый багана:
Менгән саен күбрәк чайкала.
Аңа егылмыйча менәбез дип
Җан кыела, чәчләр агара.
Авыш баганага менгән кебек
Йөгереп узыйк
Туу белән үлем арасын,
Белгән хәлдә,
Биеклеккә күбрәк менгән саен
Егылуларның
Хәвефлерәк була барасын.
Йөгереп меник әле биеклеккә,
Меник әле,
Нигә менмәскә?
Биеклектән курыкмаган җаннар
Лаек була бүләк-әтәчкә.
Йөгереп меник, алыйк әтәчләрен,
Гомеребез зая үтмәсен.
Егылып төшсәк,
Нигә кайгырырга:
Беләбез ич
Җирдән түбән беркем китмәсен.
Менүчеләр булган, егылучылар...
Бу дөньяга
Кемнәр килеп, кемнәр китмәгән.
Егылучылар җиргә егылганнар,
Җирдән түбән беркем китмәгән –
Менүчеләр барыбер бетмәгән.
Егылганның җирдә эзе калган,
Туган җирем
Ят итмәгән үзенең баласын.
Авыш баганага менгән кебек
Йөгереп узыйк
Туу белән үлем арасын.
Йөгереп узыйк әле тормыш юлын,
Бу дөньяда
Әйтеп калыйк әле әйтәсен.
Һәр адәмгә алып китү тиеш
Үзенә дигән авыш баганадан
Үзенә дигән кызыл әтәчен.

## Йомырка йөгертеш

Мәйданнарга ашыгып килеп кердем,
Изүләрне ачып, шашынып:

– Китерегез әле бер йомырка,
Китерегез әле бер кашык!
Күкәй йөгертмәгәч,
Сабантуйның
Ни кызыгы аның, ни яме.
Финишларга кадәр ватмый-нитми
Йөгертергә телим мин аны.
...Тормышка да шулай килеп кердек,
Безнең йөрәк
Яшәү дәрте белән җилкенде.
Шул чагында
Өлкән буын безгә дөнья бирде
Һәм тапшырды безгә ил-көнне,
Сабантуйда
Кашыкларга салып йөгертергә
Ак йомырка биргән шикелле.
Соңгы сулыш өзелгәнгә кадәр
Йөгертергә тиеш без аны,
Туар буыннарга исән-имин
Тапшырырга тиеш дөньяны.
Үтәлергә тиеш бу әманәт,
Ни күрсә дә егет башлары.
Тәгәрәсен җиргә безнең башлар,
Йомыркалар кебек сибелгәнче
Халкыбызның нигез ташлары.
Өлкән буын безгә биреп китте
Ак йомырка кебек дөньяны.
Киләчәккә таба ватмый-нитми
Йөгертергә тиеш без аны.

## Катыктан тәңкә эзләү

Җибәр әле, хатын, тотма җиңнән,
«Шашма, картым, тилермә!» – димә.
Сабантуйда минем
Башны катыкларга тыгасы һәм
Тәңкә эзләп карыйсы килә.
Тиле-миле чаклар байтак була,
Нишлисең бит,
Уңмадың шул инде ireңнән.
Тик шулай да җибәр әле җиңне –
Без тормышта
Һәрнәрсәне эзләп өйрәнгән.
Безнең башлар байтакны кичергән,
Хакыйкатьне эзләп, хаклыкны.
...Сабантуйда тәңкә эзләгәндәй,
Башың белән сөзеп катыкны.
Ләгәндәге ачы катык кебек,
Дөньясы да
Болгана да әле, тулгана.
Кайчагында кинәт тончыгабыз,
Хакыйкатьне
Таптык кына диеп торганда.
Аклык, хаклык табылырга тиеш,
Утка-суга
Төшсәк тә без ничә-ничә кат.

Эзләмәсәң, үзе табылмый ул,
Катыктагы талир тәңкә кебек
Ята бирә төптә хакыйкать.
Эзлик аны...
Байлык-шөһрәт өчен
Башын хилафлыкка тыкканнар,
Борыны белән пычрак ера-ера,
Хилаф эштән коры чыкканнар:
– Тилергән бу! – дисә дисеннәр,
Көлә икән, әйдә, көлсеннәр,
Йөзләренең барыбер бер дә бер көн
Караласын белеп көлсеннәр!
Кайчак мәкер өскә калкып чыга,
Ә хаклыклар
Кичегә шул әле, кичегә:
Күз алдында
Күпме Сальерилар
Күпме Моцартларга,
Шәраб диеп, агу эчерә.
...Димәк,
Бертуктаусыз без чумарга тиеш,
Хаклык эзләп,
Тормыш чоңгыллары эченә.
...Җибәр әле, хатын, тотма җиңне,
«Шашма, картым, тилермә», – димә.
Минем бүген
Башны катыкларга тыгасы һәм
Тәңкә эзләп карыйсы килә.

## Бер җырлыйсы килә сабантуйда

Бәйрәмнәрнең моңы күңелләрнең
Нинди кылларына тиядер...
Сабантуйга чыксам,
Шашып бер җырлыйсы
Һәм елыйсы килә нигәдер.
Сабантуйда, моңлы бер җыр булып,
Күңел түрләреннән
Бәреп чыга безнең горурлык.
Бәйрәмнәрнең җырлы һәр мизгеле
Көйсезләрнең
Бөтен гомеренә торырлык.
Сабантуйга ерак гасырлардан
Кайтавазлар булып җыр кайта.
Безне, ахры,
Кайта алмаганнар һәм кайталмас
Абыйларның җыры моңайта,
Көне өчен яшәмәгән алар,
«Илем, җирем!» – диеп,
Ил кайгысы белән янганнар.
Ил уза алмас упкын очраганда,
Күпер булып ятып калганнар.
Иле өчен дарга менгергәннәр,
Иле өчен
Диварларга терәп атканнар –
Сабантуйга барыбер кайткан алар;

Җырлар булып,
Легендалар булып,
Сабантуйга барыбер кайтканнар.
Җырлап кына түгел,
Җырлар булып
Кайткан алар сабан туена.
Җырлап кына гомер иткәннәрнең
Җыры калмый туар буынга.
Бүген алар безнең белән йөри,
Шунда алар, бәйрәм эчендә.
Минем канда алар, минем җанда,
Хәтеремдә яши, исемдә.
Шунысы авыр,
Мин җырларга тиеш ул җырларны
Һәм җырларга алар өчен дә.
Мин җырлыймын.
Бу җыр күңелләрнең
Нинди кылларына тиядер,
Сабантуйда минем бер җырлыйсы
Һәм елыйсы килә нигәдер.

## Биисе килә

Котылып бар дөнья мазасыннан,
Котылып бар моңсу уйлардан,
Сабантуйда түбәтәйне кырын саласы да,
Их, биисе килә, туганнар!
Биюченең бары бер законы –
Башны гына түбән имәскә!
Чулпы чылтыратып кызлар бии,
Язлар җиткәч, ата каз да бии –
Нигә безгә шашып биемәскә?
Гармунчы дус! Сыздыр «Чабата»ны,
Йөрәк ярылмаса, җан чыдар.
Кайгыларым сибелеп калсын әле,
Башлар исән булса, җай чыгар.
Фаҗигасен күрдек, кайгыларын –
Түгелер яшь инде түгелдә.
Ярсу биючедәй тыпырдатып
Биеп узыйк калган гомерне.
Читкә тайпылыгыз, мәйдан кирәк,
Башын иеп елап торганнар!
Ярсулыктан йөрәк ярылганчы,
Их, биисе килә, туганнар.

## Сабантуй беткәч

Сабан туе бетте.
Көрәшчеләр
Мәйданнардан китте дан алып.
Көрәшчеләр китте...
Өзгәләнгән
Тастымаллар калды таралып.
Тастымаллар калды
Кара җирдә,

Теткәләнеп шунда, каралып...
– Нишләвең бу, туган, Карьят батыр,
Кая киттең инде син, Алып?!
Таралмагыз әле, әй, батырлар,
Сезсез тынгы юк бит бу җанга!
...Яңа батырларны көтеп кала
Өзек тастымаллар мәйданда.

*1975*

## Танымыйсызмыни, каеннар?

Сезнең янга йөгереп килдем әле,
Уртаклашыр шатлык-кайгым бар.
Сезнең белән үскән егет ич мин –
Танымыйсызмыни, каеннар?
Нигә әле миннән ятсынасыз,
Гимнастерка кигән өченме?
Безнең белән уйнап үскән егет
Ак күлмәкле иде, дисезме?
Мин хәзер үк солдат киемнәрен
Атып бәреп уйнар идем дә...
Сезнең кәүсәләр дә күтәралмас
Җир язмышы хәзер иңемдә,
Ятсынмагыз әле, каенкайлар,
Ят итмәгез солдат киемен.
Сезнең аклыкны да саклыйм ич мин,
Бер солдаты булып җиремнең.
Сезнең янга йөгереп килдем әле,
Уртаклашыр шатлык-кайгым бар.
Сезнең белән үскән егет ич мин,
Бер серләшик әле, каеннар.

*1971*

## Кычкыр әле, кычкыр, командир...

Солдат клубында утырабыз.
Кино бара – «Үлмәс гарнизон».
Нигә тынып калдың әле син, командир,
Әтиләрнең Брестта үлүләрен
Ничек итеп тыныч карыйсың?
...Әтиләрем үлә, дошман көлә,
Кычкыр әле, кычкыр, командир:
– Минем арттан, рота!
Әтиләргә ярдәмгә! – дип кычкыр.
...Кычкырсаң да, баралмыйбыз инде,
Баралмабыз инде ярдәмгә.
Минем нәфрәтне дә аттың, әти,
Дошманыңа соңгы ядрәңдә.
Синең үч калганны күргәнгәме
Ихтыярсыз
Елыйбыз без, әти, елыйбыз.
Жәлләп түгел сезне,
Тик ярдәмгә
Баралмаган өчен елыйбыз.

*1970*

## Туган ил кызларына

«Киткән чакта үбәлмәдек тә...» – дип,
Безнең йөрәк күпме сызлады.
«Көтәбез» дип хатлар язган өчен
Рәхмәт сезгә, илем кызлары.
Хатларыгыз түш кесәдә булса,
Бар дәрманын җыеп, бар көчен,
Дөрләп янган утка керә солдат
«Сөям» дигән сүзегез өчен.
Мәхәббәтен, вәгъдәләрен сатып
Йөргәннәргә бездән мең нәләт.
Ил язмышы бассын җилкәләргә,
Тик басмасын сезнең хыянәт.
Онытмагыз, кызлар, онытмагыз:
Без кайтырбыз язга йә көзгә.
Ил алдында бурычыбыз бер үк:
Ил ышана безгә, без – сезгә.

*1970*

## Тынгысыз төн

Караңгы төн. Күзгә йокы керми,
Тыңлап ятам сәгать тавышын.
Изрәп-изрәп йоклау кирәк тә бит –
Тынгы бирми дөнья язмышы.
«Син уяумы, солдат?» – дигән кебек,
Тәрәзәдән карый тулган ай.
Солдат дуслар йоклый казармада,
Тау-таш җимереп арыган Алыптай.
Йокы аралаш сөйләшәләр кайчак,
Илен сагына алар, күрәсең:
– Әни, кайттым, каршы алырга чык...
– Килә, җаным, суырып үбәсем...
Солдат өндә солдат булып йөри,
Ә төшендә: туган ягында.
Бәлки, тревога булыр сөйгән ярын
Үбәргә дип торган чагында...
Караңгы төн. Күзгә йокы керми.
Уйлар чаба туган илләргә.
Иртәгә мин походларга китәм,
Җир язмышын алып иңнәргә.

*1970*

## Карап йөри хәрби постларны...

Караңгы төн. Дөнья изрәп йоклый,
Тик ай гына йокламый бары.
Минем белән озын төннәр буе
Карап йөри хәрби постларны.
Солдат дуслар йоклый казармада,
Изрәп йоклый – ачык колачлар.
Ыңгырашып куя йокы аралаш
Көндез строевойда
Яньчелгәләп беткән платцлар.
Ракеталар йоклый кыңгыр төшеп,
Полигоннар йоклый төш күреп,
Йокымсырый хәрби самолетлар,
Очып арган каракош кебек.
Изрәп йоклый изге Җир-анабыз,

Әйтерсең лә илләр тып-тыныч,
Күз яше дә, кан да таммый җиргә,
Дошманнар да кайрамый кылыч.
...Әйтерсең лә җирдә бар егетләр,
Сөйгән ярын чакырып,
Гармун тарта урам чатында;
...Әйтерсең лә ире куенында
Изрәп йоклый барлык хатыннар;
Әйтерсең лә
Сугыш та юк җирдә,
Дошманнар да күптән йоклаган.
Дөньядагы хәрби заводлар да
Күптән инде эштән туктаган.
Изрәп йоклый изге Җир-анабыз.
Йөзе аның
Бала көткән ана йөзедәй.
Пультлардагы ак басмалар гына
Чекерәеп ята дөньябызга,
Ачык калган мәет күзедәй.
...Караңгы төн.
Бөтен дөнья йоклый.
Тик ай гына йокламый бары.
Минем белән озын төннәр буе
Карап йөри хәрби постларны.
Тик ай гына йөри минем белән,
Пилоткасын кигән солдаттай.
Йоклап китәрләр дә, Җир-анага
Хәвеф-хәтәр килер ди бугай.

*1970*

## Әйдә җырлыйк, туган

«Ямансулыйм, илне сагынам» дип,
Түбән имә, туган, башларың.
Изүләрне чишеп бер җырлыйкчы,
Бер сибикче «Алмагачлары»н.
Башын игән солдат солдатмыни,
Еламсырый торган нинди ир?
Ачык изү өчен бер нарядны
Бирсә бирер инде командир –
Әйдә җырлыйк, туган!
Без бит әле
Тальян тартып үскән авылда.
Илләр имин, башлар исән булса,
Бер кайтырбыз әле тагын да.
Бер кайтырбыз әле,
Без бит җиргә
Гимнастерка киеп килмәгән.
Гимнастерка салу белән генә
Ил язмышы төшмәс иңнәрдән.
Елаганның яше кибә-оча,
Җырлаганның
Җыры кала җирдә иңрәп.
Җырламасак, тулган сагышлардан
Ярылып китәр сыман бу йөрәк.
Бер кайтырбыз әле,

Ямансулап
Түбән имә, туган, башларың.
Туган илгә ишетелерлек итеп
Сибик әле «Алмагачлары»н –
Шаккатсыннар безнең моңыбызга
Бу илләрнең сандугачлары.

*1971*

## Казакъ дустыма

Моңсуланып әгәр тынып калсам,
Талчыктырса поход юллары,
«Амансыңмы, доскай?» – дип сорыйсың,
Иңнәремә салып кулларың.
Шул сүзләрең шифа була миңа,
Дөрләп китә йөрәк ялкыны.
Кулларыңда халкың кул җылысын
Китерәсең миңа, ахыры.
Без бит уртак илнең балалары,
Бер семьяның ике туганы.
Никадәрле афәт кичерсәк тә,
Йөрәк исән, башлар югары.
Тормыш тамырларын капшаганда
Кара чорның кара еллары,
Җан бирергә яткан вакытта да
Пышылдаштык:
– Нык бул, туганым...
Иңнәр иңдә булып, куллар кулда,
Нинди хәтәр юллар кичелгән.
Җитәкләшеп бергә күтәрелдек
Заман сөремнәре эченнән.
Дошман килсә әгәр өстебезгә,
Сызгандык та шунда без җиңне,
Сыеныштык бергә
Чытырдатып,
Йомарланган йодрык шикелле.
Рәхмәт, туган! Шушы кулларыңда
Мәхәббәтен казакъ халкының
Түкми-чәчми миңа китергәнсең
Өермәле юллар аркылы.

*1971*

## Солдат боткасы

«Ашау ничек, улым, җитәме?» – дип,
Һәр хат саен язма, әни, син.
Монда шундый ботка пешерәләр –
Бер читтәрәк торсын бәлешең.
Өйдә синең ашны ашагач та
Киләә иде изрәп йоклыйсы.
Монда хәлләр икенчерәк икән,
Кызык икән солдат боткасы.
Ашавыбыз була шул ботканы,
Әй, җилкетә, әнкәй, йөрәкне:
«Путь далек»ны сузып җибәрәбез,
Киерә төшеберәк күкрәкне.
Дөнья шаулый безнең җырыбыздан,
Тыңлап торсаң иде бер генә.

Баскан җирдән утлар чыгып кала,
Җирләр тетри, асфальт сыгыла.
Йөгерергә торсак, җил җиталмый,
Махы бирми ботка җегәре.
Элдерәбез, әнкәй, ун чакрымны,
Палатканы җилгә җибәреп.
Уяу итте, ярсу итте мине
Бу хикмәтле солдат боткасы.
Теләк тели-тели, постта торам:
Илгә-көнгә очкын төшмәсен һәм
Газиз анам тыныч йокласын.
Ил чигендә әгәр янгын чыгып,
«Ут!» хәбәре алсак без кинәт,
Синең улың ут эченә чаба:
Сез кыйммәт бит безгә,
Ил кыйммәт!
...«Ашау ничек, улым, җитәме?» – дип
Кайгыртасың, әнкәй, рәхмәт.
Әллә мине ботка ярсу итте,
Әллә сезгә булган мәхәббәт.

*1971*

## Итек кенә туза, егетләр...

Их, Җир буйлап күпме җилдердек без
Соры шинель, кирза итектән.
Барысына түзеп була икән,
Итек кенә туза, егетләр.
Авыр походларда йөргән чакта
Тиргә батып утта янасың.
Без басканны дөнья ишетсен дип,
Дагаларның суктык яңасын.
Солдат күңеленнән җырлар таша,
Ташка бәрелеп дага чыңласа.
Дөньяларның иминлеген сөйгәч,
Йөрәк түзә, итек чыдаса.
Солдат үзенең йөгерә алмаганын
Күрә, диләр иде, итектән.
Безнең исә ярсый-ярсый чабып
Теткәләнеп бетте итекләр.
Илгә булган сөю гел яңарды,
Итек кенә тузды, егетләр.

*1971*

## Әдәпсез син, кызый...

Элемтәче булып эшлисең син
Мин контролер булган штабта.
Әдәпсез дә кызый син, Марина,
Әйтми булмый инде шул хакта.
Көяз аккош сыман «йөзеп» кенә,
Иртә белән эшкә киләсең.
– Пропускыңны күрсәт, – дип сорасаң,
Елмаясың, кызый, көләсең.
Мин бит инде күзле-башлы кеше –
Анысын да яхшы беләсең.
Рөхсәт-фәлән сорап тормый гына
Күңелемә нигә керәсең?

Башканың бит гөле үсә анда,
Син шуларны таптап үтәсең.
Күңелемнең гүзәл багларында
Теләгәнчә гуләйт итәсең.
Йөрәк ансы өйләнмәгән дә ул –
Акыл ай-ваена карамый.
Тик шулай да кеше бакчасына
Рөхсәтсез керү
Ярамый бит, кызый, ярамый.
Әдәпсез син, кызый,
Чит бакчага кереп
Сокланасың кеше гөленә.
Бер контролер куймый булмас инде
Күңелемнең ишек төбенә.

*1971*

## Исмәле, җил...

Исмәле син, заман җиле,
Йөзгә бәреп исмәле.
Син кодрәт иясе булсаң,
Ә без кеше ич әле.

Рухымны иеп иркеңә,
Алырга теләп мине
Бәргәләмә анда-монда.
Без дә хәзер
«Флюгер» түгел инде.

Сибелер яшь, сибелер чәч,
Сез бәреп искән чакта.
Әмма инде китә алмыйбыз
Чәчләр сибелгән якка.

Исмәле син, заман җиле,
Йөзгә бәреп исмәле,
Син кодрәт иясе булсаң,
Ә без кеше ич әле.

*1981*

## Әй, бөек зат рухы, үрсәләнмә...

Вафаты алдыннан Гаяз Исхакый үзенең кызы Сәгадәттән: «Мин үз илемдәме?» –дип сораган. «Үз илеңдә, әти», – дигәч, ул канәгать елмайган һәм күзен мәңгегә йомган.

«Уйладым мин: соңгы сулышымда
Үз җиремдә
Кылып китим дидем гыйбадәт...
«Үз илеңдә» диеп, әткәеңне
Алдадың ич, кызым Сәгадәт», –
Дип, хәзер дә рәнҗеп ятадыр күк,
Чит туфракны үбеп, чит илдә.
...Язлар җиткәч, акчарлаклар булып
Рухы кайта барыбер Иделгә.
Ак бүреләр булып карап йөри
Җаекларын, Урал буйларын.
Ап-ак сөлге булып чайкалып, ул

Айкап йөри сабан туйларын.
Ямансызга иман булып керә,
Вөҗдансызның уята вөҗданын.
Сансызлыкка төшкән кавеменең
Күтәрәм дип шөһрәтен-данын.
Кара көйгәннәрнең аклык сибеп
Агартырга теләп җаннарын
Бәргәләнә ул рух...
Фәндәс булып сөйли парламентта,
Туфан булып калка сәнгатьтә,
Зәки булып йөри мәйданнарда,
Илгә-көнгә ныклык өләшә ул,
Кашаповлар булып, һәрьякта.
Батырлыклар бирә куркакларга,
Гайрәт бирә көчсез ирләргә.
Дөнья буйлап оран салып йөри
«Кайтыгыз, – дип, – туган җирләргә!»
Чын хакыйкать булып бәгыренә,
Миенә керә илбашларының.
Татлылыгын сөйли, ачылыгын
Милләт түккән күз яшьләренең.
Бәгырьләрдән, күңел төпкеленнән
Җан авазы булып ул дәшә:
«Әй, милләтем,
Үз җиреңә хуҗа булгангача
Тырыш, көрәш, тартыш – мең яшә!
Инкыйразлык юлын сайларгамы,
Ничә гасыр буе түз-түз дә...»
Әй, бөек зат рухы, үрсәләнмә:
Дәүләт күрми – үлем юк безгә!

*2000*

## Сөембикәне чакыру

Язмышыма хуҗа булып
Кайт син, зинһар, Сөембикә.

*Разил Вәлиев*

Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Авыр безгә, авыр синсез тору.
Бер егылгач авыр икән тору
Һәм яңадан дәүләтеңне кору.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Әле һаман
Явыз Иван йөри җиребездә.
«Торыгызчы, ирләр!» дип оран сал,
Тору кирәк
Дәүләт килсен өчен илебезгә.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Ике башлы
Каракошлар оча күгебездә.
Аннан башны комга тыгып кына
Котылу уе әле күбебездә.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Башын комга тыгып
Качып ятканнарга әйт сүзеңне:
«Каракошлар мәетеңне көтә,

Башың күтәр, татар, ач күзеңне».
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Татарлыгын җуя балаларың,
«Без нугайбыз» диеп нугайларың,
«Без себербез» диеп себерләрең...
Җыюларың кирәк, барлауларың.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
«Мәскәү оҗмах»ына әйди-әйди,
Кемдер үз-үзенә элмәк бәйли,
Кемдер Шаһгалиләр шаен шәйли.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Рух саекты, җаннар ярлыланды.
Юату юк моңлы-зарлыларны,
Аера алмыйбыз байны, ярлыларны...
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Милләттәшләр милләттәшен «ашый».
Сөйлә безгә, гыйбрәт итеп сөйлә:
Шуның аркасында кыелдылар
Күпме илләр, күпме ирләр башы...
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Рухи афәт килде Идел-йортка.
Ата-ана азып-тузып йөри,
Балалары сыктый приютта.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Фәхишәлек басты,
Имансызлык басты дөньябызны,
Сәрхушлекләр килде илгә-көнгә –
Белми ата улны, ана – кызны.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Иман кайтар әле имансызга,
Мәнлелекләр кайтар мәнсезләргә,
Нәзакәтлек кайтар хатын-кызга.
Кайт инде, кайт безгә, Сөембикә,
Өмет кайтар әле өметсезгә.
Денен кайтар әле денсезләрнең,
Иман нурын кайтар йөзебезгә.
Кайт әле, кайт безгә, Сөембикә,
Ник дәшмисең, аваз салчы, бикә.
Илгә – дәүләт, рухка – ныклык алып
Кайтчы инде,
Халык бәгърендәге Сөембикә.

*2001*

## Судка бирәм!

«Миңа кем каршы – барысын да судка бирәм».
*Берәүнең суд залында әйткән*
*шул сүзләренә киная*

Дөнья бара рөхсәт сорамыйча –
Яратмыйм бу кире дөньяны.
Миннән сорамыйча барган өчен
Судка бирәм әле мин аны.
Миннән сорамыйча ник җил исә,
Нигә ява икән бу кары?
Миннән сорамыйча яуган өчен
Судка бирәм әле мин аны.

Миннән сорамыйча кояш чыга,
Нигә ата микән бу таңы?
Миннән сорамыйча аткан өчен
Судка бирәм әле мин аны.
Ә бу еллар нигә уза икән,
Алтмышларга китте бит саны.
Миннән сорамыйча узган өчен
Судка бирәм әле мин аны.

*1999*

## Этнографик карта янында

Татар халкының этнографик атласын карасаң, Рәсәй биләмәсе татар ямаулыклары белән ямалган иске чикмәнгә охшап тора.

Белдең микән, Рәсәй, итәк кисеп
Җиңең ямап гомер итәсең.
Синең хәлең – иске чикмән хәле,
Шулай язган... ни хәл итәсең.
Синең чикмәнеңне тарсынганнар
Әнә нинди йортлар җиткерде.
Ә син һаман тишек чикмән ябынып,
Исереп яткан мужик шикелле
Сүгенәсең,
Аермыйча акны, караны...
Беләсеңме икән: чикмәнеңнең
Ертыгын бит татар ямады.
Шашкан аю кебек үкерәсең,
Акырасың чикмән астыннан:
– Татар шулай итте, болай итте,
Татарлар бит алар баскыннар!
Җир минеке, диеп дулап йөрдең,
Җан кыйраткыч дигән дан алып.
Ямаулыгың тия күрмә берүк –
Чикмәнең дә китәр таралып.
Үз хәлеңне ямаулыктан күрмә,
Чикмәнең бар – йокла син, Рәсәй.
Ябынырга чикмән калсын дисәң,
Ямаулыгың сакла син, Рәсәй.

*2002*

## Кире алу кирәк Казанны!

Тарих төпкеленнән чорлар аша
Өне килә кебек бабамның:
– Исән булсын дисәң үз кавемең,
Кире алу кирәк Казанны.

«Кире алу кирәк!» дип, угымны
Ничә кабат агуга мандым.
Атыйм дисәм, дошман күршем булган,
Рухы гына калган дошманның.

Ул явыз рух безнең өстебезгә
Минут саен этен өстерә.
«Иман дигән кылычыңны ал да,
Әйдә, милләт, Казан өстенә!» –
Дип кычкыра йөрәк үрсәләнеп.
Яклаучы юк илдән язганны.

Исән калсын дисәк кавемебез,
Кире алу кирәк Казанны!

Кире алу кирәк,
Куу кирәк
Эт өстергән ул явыз рухны.
Башкалага иман иңми торып,
Кынга тыгып булмый кылычны.

Баш өстенә кылыч күтәрдек без:
Әйтче, вөҗдан, кая чабасың,
Өйрәт, тарих, үзең гомер иткән
Калаларны ничек аласын!
...Без яу чыктык Казан тарафына
Кылыч итеп вөҗдан, иманны.
Исән калыйк дисәк, явыз рухтан
Тартып алу кирәк Казанны.

*2000*

## Кайтавазлар булып тавышың калды...

*Марат Мөлеков үлеменә*

Империянең тынчу сазлыгында,
Үлем көтеп, ай-һай, күп яттык.
Шулчак безгә Себерләрдән килеп
Оран салдың: «Кузгал! Азатлык!»
Баш күтәреп кенә караулар да
Үлемгә тиң булган көннәрдә
Бар буеңа басып оран салдың:
– Ил язмышын алып иңнәргә
Кузгал, татар,
Йөрәгеңдә сүндемени
Азатлыкка чыгу теләге.
Күтәрелче, Себер, кузгал, Курган,
Кыймшан, Казан, Уфа, Чиләбе!
Империянең тынчу сазлыгында
Ирек көтеп яту файдасыз.
Тавыш бирче, Җаек, Әстерханнар,
Сергач мишәрләре, кайда сез?
...Оран сала-сала китеп бардың,
Киләчәккә сине озаттык.
Кайтавазлар булып тавышың калды:
– Кузгал, татар, кузгал! Азатлык!

*1997*

## Колшәриф монологы

Хәтер көннәрендә безләрне дә
Искә аласыздыр дип белдем мин.
Мин – Колшәриф рухы –
Уналтынчы гасыр уртасыннан
Варисларны күрим дип килдем мин.
Дәвер аша юллар ябык булды,
Күрешә алмадык, йөрмәделәр хатлар.
Шушы күрешүләрнең хөрмәтенә
Йә, бер дога кылыйк: «Аллаһ әкбәр!»
Колшәрифләр булган, шәһит киткән

Дип беләсез икән бик күбегез.
Сезнең җанда рухым исән икән,
Мәчет итеп
Күтәрәсез икән бит – күрегез!
Мәчет булып бассын дидегезме,
Мәңге торсын диеп җан сагында.
Саумы, варисларым, изге Казан!
Танымыйм да сезне һәм таныйм да.
Өзелеп-өзелеп карыйм
Ышанмыйча,
Карап куям янә бер тагын да:
Чыннан да сез безнең варисларммы?
Безнең кавем һәм дә шул каннанмы?
Башкалада чиркәү чаңын тыңлап
Аттырасыз икән ич таңнарны.
Җырыгызга колак салып карыйм:
Чит аһәңнәр тиядер күңелгә.
Сөйләмегез тыңлыйм һәм аптырыйм –
Татарча да кебек һәм түгел дә.
Борынгыдан килгән шанлы исемең,
«Эшчән» исемең һаман да бар икән.
Эшләгәнең тартып алалар да,
Кире алу юлы бик тар икән.
Сату-алу кызу бара икән,
Арзан түгел икән кешелекләр.
Бар дөньяны хөсетлекләр баскан,
Бар гавамны баскан көнчелекләр:
Камай Морзаларның, Шаһгалинең
Исән икән әле нәселләре.
Элеккечә илен-көнен сатып
Гомер итү икән кәсепләре.
Үзенекен онытып, күршеләрнең
Күтәргәнсең мәдәниятләрен.
Үз кальбеңдә хәзер махмырлы рух,
Бозыклыгы кергән чит-ятларның.
Хәзер инде үкенәсең бугай:
Кая китте данлы, шанлы чаклар?
Бетүеңме инде бу, милләтем,
Ясин укыйкмыни – «Аллаһ әкбәр!»
Төсең генә киткән, өметең бар,
Күңелеңдә күрәм
«Дәүләт төзим» дигән уең барын.
Һәм ниндидер курку-шүрләүләрне,
Юхалану гамен күрәм тагын.
Юхаланып дәүләт төзеп булмый,
Дәүләт тотып булмый икәнлеген,
Кан-яшь түгеп, елап һәм ялварып
Ирек алып булмый икәнлеген
Тарих мең кат исбатлады инде –
Моңа өмет итмәң, әй, варислар!
Чигенүләр аршын белән булса,
Ә җиңүләр килә тик карышлап.
Яуга чыксаң, уңын-сулын кара –
Көрәштәшең бармы яннарыңда?
«Миңа ут-күз тими, бигайбә» дип
Тормаслыкмы алар,

Синең илең утта янганнарда.
Җиңәм дисәң, рухыңны дәвала
(Җиңәм димә махмырлы рух белән),
Иманыңны ныгыт, кальбең пакьлә –
Шул чагында
Богауларны өзәсеңне беләм.
Хәтерең бар әле, җаның көйри.
Дәүләт торгызырга
Өметең бар әле – рух сүнмәгән.
Кол язмышын бик күп татысаң да,
Җаның богауларга һич күнмәгән.
Көчең барда, рухың, җаның барда
Бер талпынчы – бәлки, соңгысыдыр.
Шундый итеп талпын, шундый итеп –
Коелып төшсен кулларыңнан зынҗыр.
Кара төсне җиңәр өчен җирдә ак бар,
Баш өстеңдә безне саклар Бөек Хак бар.
Алда синең соңгы көрәш, кузгал, татар:
«Аллаһ әкбәр! Аллаһ әкбәр! Аллаһ әкбәр!»

*2001*

## Авылдашларыма

Рәнҗү күреп җаннар кыелганда,
Тәгәрәшеп яшьләр коелганда,
Сиңа сыенам, авылым Күчтәнти Баш*,
Әниемә килеп сыенгандай.

Җир йөзеннән инде югалсаң да,
Кайда йөресә дә газиз башлар,
Авыр чакта «Кем кимсетә?» диеп
Йөгереп килеп җитә авылдашлар.

Үгетлиләр мине: «Шундый чакта
Безне чакыр, якташ, – диләр алар, –
Зилзиләле заман эчләрендә
Без килмәсәк, сине кем аралар...»

Авыр көрәшләргә чыккан чакта,
Авылдашлар минем гел янәшә.
Аксакаллар, таяк изәп миңа:
«Иманыңны сакла!» – дип эндәшә.

«Иманыңны сатма! – ди Ак әби. –
Кер кундырма, улым, ак җаныңа.
Авызың тулы кара кан булса да,
Күрсәтмәскә тырыш дошманыңа.
Кайгы килсә, улым, сыгылып төшмә,
Адарынып китмә, шөһрәт алсаң.
Сөенербез, вөҗданыңны саклап,
Рухи биеклектә кала алсаң...»

Кая барып, ниләр күрәсе бар,
Белмим, тәкъдир тагын кая ташлар?!

Саклап килә мине Күчтәнти Баш,
Саклап килә мине авылдашлар.

*2000*

## Картлык килгәндә

Яшьлегемдә туйганчы бер
Җырлармын дигән идем.
«Моңлы бала – гомерсез» дип
Искәртте туган илем.

Яшьлегемдә туйганчы бер
Көләрмен дигән идем.
«Күп көлсәң, еларсың» диеп
Искәртте туган җирем.

Яшьлегемдә туйганчы бер
Уйнармын дигән идем.
«Азрак уйна, күбрәк уйла»
Дип әйтте туган илем.

Яшьлегемдә туйганчы бер
Яшьнәрмен дигән идем.
«Яшен уза, яшә генә»
Дип әйтте туган җирем.

Яшьлегемдә мәңге-мәңге
Яшәрмен дигән идем.
«Дөнья фани, балакаем»
Дип әйтте туган җирем.

...Хәзер чамалап уйныйм да
Чамалап кына көләм,
Чөнки барыбер туйганчы
Яши алмасын беләм.

*2002*

## Каз өмәсе

Кыр казлары артыннан
Биеклеккә тартылам...

*И.Юзеев*

Кыр казлары оран салып
Китә кыйбла ягына.
«Әйдә, без дә кузгалыйк!» – дип,
Йорт казлары кагына.

Ярсымачы, әй, йорт казы,
Китәм диеп ярсыма.
Барыбер очып китә алмассың
Хыялларың каршына –
Каз өмәсен каршыла.

Әй, кыр казы, оран салма
Йорт казлары халкына.
Киләчәкләре – сугымдыр,
Ничек ярсы-ярсыма.

Каз өмәсе...
Кемгә бәйрәм,
Кемгә сугым пычагы,
Кемгә ядәч, кемгә кәләш,
Кемгә кияү кочагы...

...Йорт казының язмышларын
Язмасын иде тәкъдир.
Әй, Илаһым, өммәтемә
Кырказ хөрлекләре бир!..

*2002*

## Әнчек этләр

Аю атучылар бик зирәкләр,
Белә алар нәрсә-ни кирәк.
Аю атыйм дисәң, иң әүвәле
Хәйлә кирәк, әнчек эт кирәк.
Тәртибе бар: әнчек эт аюны
Аннан чәйни, моннан өстери.
Аю, мескен, әнчек белән мәшгуль,
Ә сунарчы мылтыгын тери.
Әнчек этләр барсына да өрә –
Аюга да, очар кошка да.
...Сак бул, кеше, бу безнең дә язмыш:
«Әнчек» өрсә, син дә мушкада...

*2002*

## Югалмабыз

Язгы ташу вакытында Гайнә әбинең Тол елгасында казлары агып киткән, ди. «Казым акты, казым акты!» – дип кычкыра башлагач, аннан: «Ничәсе акты?» – дип сораганнар. «Бары да, бары да», – дигән әби. Шул вакыйгадан соң Барданы «Каҗмакты» һәм «Барда» исемнәре белән атап йөртә башлаганнар, имеш.

*Риваятьтән*

Ил анасы, «Казым акты» диеп
Үрсәләнмә Толның ярында.
Ташуларда аккан бәбкәләрең
Кайтты инде, кайтты бары да.

Бәбкәләрең без бит, Ил анасы,
Кайттык менә – басып торабыз.
Җыр язабыз, бала үстерәбез,
Җир сөрәбез, чәчә-урабыз...

Шушы җирдә безнең бәхетебез,
Тәхтебез дә шунда – беләбез!
«Барда җыен»* көен ишетүгә
Казлар кебек очып киләбез.

Үрсәләнмә берүк, Ил анасы,

Бәбкәләрең кайтты бары да.
Тол булмабыз әле, Тол барында,
Югалмабыз, Барда барында.

*2000*

## Тимә әле миңа, агымсу...

Сагыш басса, йөгереп Толга төшәм,
Тол сагышны алып китәр дип.
Сулар түгел, анда елга булып
Гомерем агып ята икән бит.

Гомеремнең яшел җәйләреннән
Китүләре бигрәк ямансу.
Айларымны, елларымны ал да,
Ә үземә тимә, агымсу!..

*2000*

## Без мәңгегә синдә, Барда җире!

Мең рәхмәтле сиңа,
Иңдергәнсең
Кальбебезгә «татар» дигән исем.
Без мәңгегә синдә, Барда җире,
Егылсак та,
Егылырбыз сине үбәр өчен.
Ярсуларым бүген бәйрәм булып
Мәйданнарга чыкты ташып-тулып.
Бабаларым дәвер мөнбәрендә
Торалар күк сиңа дога кылып.

Килеп чыга кебек акбүз атта
Ак чалмалы батыр Батыршалар,
Оран салып:
– Иманыңны сатма,
Имансызлыкларга батырсалар.
Әйтерсең лә, кулына байрак тотып,
Казанбаев* йөри бәйрәмнәрдә.
Солтанморат бабай, Зәбир агай**
Елмаешып тора мөнбәрләрдә.

«Бу безнең җир!» диеп, Гайнә илен
Тол елгасы алган күк кочаклап,
Җиде тауда җиде учак ягып,
Җиде газиз*** тора безне саклап.
Борчуларым, яну-көюләрем,
Бар җырларым, Барда, синең хакта.
Милләтемнең назлы бер гөле син,
Йодрык булып
Йомарлана белдең кирәк чакта.

Рәхмәт, илем, иңдергәнең өчен
Кальбебезгә «татар» дигән исем.
Без мәңгегә синдә, Барда җире,

Егылсак та,
Егылырбыз сине үбәр өчен.
*2000*

## Әй, биедек...

Әй, биетте язмыш...
Гомер буе
Аның кубызына биедек.
Иң әүвәле әнкәй чәбәк итте –
Аның чәбәгенә биедек.

Егет булып җиткәч, «Күрсеннәр!» дип
Биеп йөрдек кызлар катында.
...Ә аннары үзенең кубызына
Биеткәләп алды хатын да...

Тора-бара бала-чага туды –
Алар кубызына биедек.
Милләт кушты, «Әйдә, бие!» – диде. –
Милләт кураена биедек.
Гомеребез шулай биеп үтте,
Биедек тә шулай биедек.

Әй, биетте язмыш...
Биюләрнең
Биедек без барсын, барсын да.
Тик тиранга башны имәдек без,
Йөгәнмәдек дошман каршында.

Башны горур тотып биеп уздык
Сикәлтәле язмышлар аша.
Тормыш нинди көйне уйнаса да,
Безнең бию булды татарча.

Бии-бии иллеләрне уздык,
Алтмышларга җиттек бит инде.
Йөрәк һаман биюләргә чыга,
Чаптар атлар
Бәйгеләргә чыккан шикелле.
*1991*

## Шашкан аю килә өстебезгә

Закон – тайга,
Медведь – прокурор.

*Рус халык әйтеме*

Аю хуҗа монда, тайга – закон,
Бар дөньяны курку, шом баскан.
Тетри гавам: Рәсәй тайгасында
Яраланган аю адашкан.

Үлем исереклеге кергән аю
Бар тайганы йөри кыйратып.
Аю түгел, империя рухы
Йөри шулай дөнья буйлатып.

Барып чыга Балкай тауларына,
Азияда йөри үкереп.
Кавказ буйларында шашып йөри,

Җан кыйратып, таптап, үтереп.

Аюларда аю каны кайный,
Геналары дәшә: «Мин хуҗа!»
Явыз Иван булып җан кыйрата,
Петр патша булып кул суза.

Көчсезләрне сытып, көчлеләргә
Аю хезмәтләре кылмакчы.
Истанбулда шайтан туе ясап,
Һинд океанда итек юмакчы.

Яраланган аю йөри җирдә,
Ике күзен кара кан баскан.
«Хуҗагыз – мин!» диеп, тәкәбберлек
Урманына кереп адашкан.
Илдә йөри яраланган аю –
Сакланыгыз, аю түгелләр!
Шашкан аю үткән сукмакларда
Җан кыелган, каннар түгелгән...

Күрәсеңме моны, и Илаһым,
Күрәсезме, илләр, халыклар?!
Тарих төпкелендә ыңгыраша
Күпме дәүләт, күпме ханлыклар!..

Безнең өскә күпме басты инде
«Империя» атлы бу аю.
Менә тагын үкереп өскә килә
Шул ук аю, шул ук масаю...

Арт санына күпме атсалар да,
Үлми икән аю нәфесе.
Акылы җитми аның: һәрбер көннең
Иртәсе бар, төше һәм киче...

...Шашкан аю килә өстебезгә,
Үлем исреклеге
Томалаган аңын һәм җанын.
Безгә килә, исән калуларның
Хәстәрен күр, Татарстаным!

*2000*

## Моң бураны

*Вафирә Гыйззәтуллина вафатына*

Ком бураны, ком бураны
Оренбурның урамы.
Илдә көрәш барган чакта,
Өйдә ятып буламы.

*Вәфирә Гыйззәтуллина*
*яратып җырлаган җырлардан*

Илдә буран, күз ачкысыз буран.
Таңга ерак әле, төн кара.
Бүре улый Рәсәй урамында,
Ихатаны аю актара.

Бүре улый Рәсәй урамында,
Илгә-көнгә курку, шом керде.
Шундый төндә: «Йокламагыз!» – диеп,
Тәрәзләрне кагып кем йөрде?

Давыл булып, тәрәзәләр кагып,
Ул йөрде бит,
Кара төндә чыра яндырып,
Давыл китеп барды,
Җаныбызда
Моң бураны гына калдырып.

*2001*

## «Таш бәгырь»

Бәхет илләренә йөгергәндә,
«Барып җитик, – диеп, – көч барда»,
«Таш бәгырь»гә бәрелүләр булды,
Бәрелгән күк калын диварга.

Игелек тә юк анда, изгелек тә,
Тиен тормый кеше кадере.
Якты хыялларның зираты ул,
Риясызлар җаны кабере.

Дивар эргәсендә кеше зары,
Ватык язмыш, өзек гомерләр...
Шушы җирдә күпме гөнаһсызның
Якты өметләре күмелгән.

Күпме җанның хыялларын кискән
Канлы яшьләр каткан бу дивар.
Җанны кыеп монда, яшьне коеп,
Чынны ялган белән бутыйлар.

Шул диварлар аша язган безгә
Бәхетебезгә таба юл яру.
Таш диварны аударырга була,
«Таш бәгырь»не авыр аудару.

Ә юлчылар йөрми тормас әле,
Бәхет-сәгадәткә юл ярыр.
Тормыш юлларында аларны да
Сагалап торыр инде «таш бәгырь».

...Әй, юлчылар, үтә-сүтә барып
Бу тормышның
Таш диварын, каты бәйләрен
Имин үтегезче, юлыкмыйча
«Таш бәгырь»гә, бәгырькәйләрем!

*2002*

## Каз каурые

Каз каурые оча, каз каурые,
Каз каурые оча җилләрдә.

Каз каурые хәлләрендә без дә,
Башка ялгызлыклар килгәндә.

Каз каурые оча, газиз башка
Каурый булып кайгы ишелә.
Каерылган каурый язмышлары
Ялгызлыкта калган кешедә.

Каз каурые оча һаваларда,
Каурый ага агымсуларда.
Гомеркәем каз гомере микән,
Каурый ява барыр юлларга.

Каз каурые оча һаваларда,
Сыеныр җай кирәк аңа да.
Ачы язмышларны узмыш өчен
Сыеныр җан кирәк дөньяда.

*2002*

## Ялгызлык

Маңгайларга уелып язылгандыр,
Язмышлардан юктыр ул узмыш.
Явызлыгын күрдек бу дөньяның,
Ялгызлыгын бирмә, и язмыш.

Кайгыларны гомер дәрьясына
Саллар итеп салып агыздык.
Кеше булыйм кеше арасында –
Тимә инде миңа, ялгызлык.

Кайгы-хәсрәт ялгыз башка килә,
Моңаймыйлар алар ишлеләр.
Авырлыктан түгел, ялгызлыктан
Аралагыз мине, кешеләр.

Кайгы килә башка, ә шатлыклар
Кичегә шул һәрчак, кичегә.
Кайгы китсен өчен, ише белән
Бергә булу кирәк кешегә.

Фаҗигаләр, ялгышулар белән
Сынап карый безне язмышлар.
Әй, кешеләр, бергә булсак кына,
Безгә язмышлардан узмыш бар.

*2003*

## Иртә килдек бугай...

Иртә килдек бугай бу дөньяга,
Иртә килдек, иртә китәбез.
Иртә китәбезме, соңракмы –
Мәңгелек юл өмет итәбез.

Мәңгелекнең эргәсенә кадәр
Тормыш йөген тартып барабыз.
Чардуганнар булып утырып кала
Юл буенда гомер арбабыз.

Утырып кала гомер арбалары,
Җыяр ризык, кылыр эш кала.
Уйланасы уйлар, хыял кала,
Сөйгән ярлар кала башкага.

Иртә килдек бугай бу дөньяга,
Туктый бугай гомер арбасы.
Иртәләү дә ярар, мәңгелектә
Мәңге-мәңге әле барасы.

*2003*

### Туган телемә

«Якла мине» дип ялынма,
Елама, туган телем.
Минем телем – горур тел ул,
Теләнү теле түгел.
«Телем бар һәм илем бар!» дип
Кинәнү кирәк бүген!

Офтанма: заман бүлде дип
Илемне телем-телем.
Илләр дә җөйләнер әле,
Сау булсаң, туган телем.

Инде телдән язу булмас,
Якадан алмас үлем.
Татарча яңгрый галәмдә
«Без исән!» дигән өнем.

Синдә без оран салабыз:
«Мең яшә, туган илем!»
Теләнү теле түгел син,
Кинәнү теле бүген.

Яшәсен дисәң милләтең,
Сау булсын дисәң денең,
Җитте тираннар алдында
Таләпләр куяр көнең.

Көндәшләрдән көнләшүле
Көннәрең инде үтте.
Тиңнәр белән тиңләшергә
Көрәш көннәрең җитте.

Иңрәп еладың, туган тел,
Илне кырау сукканда.
Кырау сукканда сыктадың,
Яуга чыккач сыктама.

«Якла мине!» дип ялынма,

Елама, туган телем.
Минем телем – горур тел ул,
Теләнү теле түгел.
«Телем бар һәм илем бар!» дип
Кинәнү тиеш бүген.

*2005*

## Карман урманы

*(Без балачакта Карман авылы
мәктәбенә урман аша йөреп укыдык)*

Тормыш безне байтак сынады шул,
«Иркә бала» диеп тормады.
Хәвеф-хәтәр килсә, курку басса,
Бармак яный Карман урманы.
Язмыш биргәненнән куркулар юк,
Нәрсә соралса да корбанга.
Моның өчен мәңге бурычлымын
Карманга һәм кара урманга.
Балачакта шунда өйрәндек без
Курыкмаска кара урманнан.
Курку басмасын дип җырлап керә,
Җырлап чыга идек без аннан.
Еллар үтте...
Күрергә дип кайттым:
Карурман дип керсәм – шыр ачык!
Төпләр арасында адашып йөри,
Елап йөри минем балачак.
Урманга дип керсәм, куакларга,
Чәчләргә дә инде бәс сарган.
Бу урманга хәзер сыктап керәм,
Сыктап чыгам хәзер мин аннан.
Тормыш безне байтак сынады шул,
«Иркә бала» диеп тормады.
Еласак та, куркып еламыйбыз,
Шундый итте
Карманымның кара урманы.

*2005*

## Бәйрәмнәр

Бәйрәмнәрдән башлар чыкканы юк,
Җырлап-биеп гомер итәбез.
Бер бәйрәмне бәйрәм итәбез дә
Икенчесен зарыгып көтәбез.

Уйлар урынында уйныйбыз без,
Елар урынында көләбез.
Кайгылар юк безнең, шатлыклар күп –
Бәйрәмнәрдә гомер сөрәбез.

Киләсене уйлап баш ватмыйбыз –
Киләчәкне белә түрәбез.
Киләчәкләр тоташ бәйрәм икән,
Шат күңелле шуңа күрә без.

Гомеребез уза бәйрәм итеп,

Мәзәк тыңлап, биеп, типтереп.
Гомер буйлап җилдерәбез генә
Тройкалы атлар җиктереп.

«Парлар табып биюгә төшәбез,
Белмичә дә кемнең кемедер.
Безнең бию бию түгелдер ул,
Гамебезне таптап күмүдер.

Рәсәй иле, бәйрәмнәрең белән
Оныттырма илем-көнемне!
Болай барсак, киләсе буыннар
Бәйрәм итәр безнең үлемне.

*2004*

## Бурычлы кеше зары

Бурычлы үлмәс,
Көн дә күрмәс.

*Мәкаль*

Бурычлардан котылу булмасмы дип,
Ният кылдым үлеп карарга.
Чакыруым булды, әҗәл иптәш
Килеп җитте җанны алырга.
Коткар, мәйтәм, бурыч газабыннан,
Килүеңә рәхмәт җан сорап.
Булмый инде, мәйтәм, җанны асрап,
Бурыч баштан ашты бит, брат.
Уңга баксам – бурыч бирәсем бар,
Сулга баксам – әҗәт бирәсе.
Шушы газаплардан котылыплар
Ничек кенә гүргә керәсе.
Әҗәлкәем, җаным, бер җаен тап,
Туктат, мәйтәм, тизрәк йөрәкне.
– Бурычыңны түлә, бәндә! – ди бу. –
Әҗәтлеләр безгә кирәкми.
Бурычлыга үлем юк ул, бәндә,
Түләп бетер – аннан карарсың...
Мин дә инде ике килеп йөрмәм,
Бурычың беткәч, үзең барырсың.
Әҗәтлене хәтта әҗәл алмый,
Бурычлының хәлен ул белми:
Үләр идем – әҗәтләрем бик күп,
Яшәр идем – бурыч көн бирми.

*2004*

## Туган авылым сабан туе

Таралып юкка чыккан туган авылым Күчтәнти Баш урынында соңгы елларда сабантуй уздыру гадәткә кереп китте.

Авылдашлар, сабан туе җитте,
Әзерләдегезме бүләкләр.
Мин бу – Рәшитегез!
Сөрән салам –
Түзеп буламыни йөрәккә?
Мәхмүт абый, сыздыр тальяныңны,

Җәүдәт абый, җырла – син кайда?
Кая киткән икән Аккай бабай?
Әллә кая Сылу тутай да.
Син кайда соң, Габибрахман абзый,
Нигә биемисең дулатып?
Бер җырлачы әле, Хәмит абый,
Яшь кызларны авыр сулатып.
Авылдашлар, сабантуйлар җитте,
Эш-көшләрне бүген ташлаек.
Гариф бабай, давай ат мылтыгың –
Сөрән сугуларны башлаек!
Язлар җитсә, җан авазы белән
Оран салып авылдашларга,
Өзгәләнеп йөрим авыл буйлап –
Тик чыкмыйлар капка ачарга.
Йөрмәс идем болай өзгәләнеп,
Үзегез бит шагыйрь иттегез.
Шагыйрь иттегез дә,
Ә үзегез
Әллә кая китеп беттегез.
Мин тилмереп йөрим япан кырда,
Авылымның
Һәр куагы белән сөйләшеп.
«Сез кайда соң?» дисәм,
«Без монда!» ди
Зират каеннары шаулашып.
Мине шагыйрь иткән авыл китте,
Әйтеп китте:
«Онытмачы мине, и улым».
Үлгән авыл буйлап җаным йөри,
Сөрән сугып йөри өй борын.
Ызба саен туктап, барлап йөри:
Кемнәр киткән, кемнәр көткәннәр.
Минем җанда авыл исән әле,
Күптән кайткан илдән киткәннәр.
«Ник киттегез?» диеп үксерәгән
Үксез каеннарга ни әйтим?
Туган җирдә үскән сез ятимме,
Әллә илен җуйган мин ятим?

*2004*

## Булдырабыз!

Булдырабыз!
Без бит шундый халык:
Авырлыклар безгә нипочем.
Авырлыкны тартып өйрәнгәнбез,
Уйламыйбыз: нигә, ни өчен?
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Бөтен миргә данны тараттык.
Шаккатырдык мирне,
Башкаларны
Үзебездән күбрәк яратып.
Булдырабыз.

Без бит шундый халык:
Ташлар басса, чыктык таш ярып,
Башкаларга зурлык яулап йөрдек,
Үзебезне хурлыкка салып.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Төгәл үтәп өстән кушканны
Олпатларны олтан итәбез без,
Солтан итәбез дә куштанны.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Солтаныбыз: «Шым тор!» – дип әйтсә,
Төртсәләр дә, күткә типсәләр дә,
Дип торабыз: «Рәхмәт, ләббәйкә...»
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Яшәвебез мисле эш аты.
Гомеребез уза, убырларга
Таш атканы саен аш атып.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Көе килми диеп тормыйбыз,
Үзебезнең көйгә биемичә,
Башкаларның күңеле булсын диеп,
Арып егылганчы биибез,
Тамак ертылганчы җырлыйбыз.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Көрәшләрдән чыкмый башыбыз.
Көрәшергә сәбәп табалмасак,
Бер-беребезнең башын ашыйбыз.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Яз-җәй гөрли кала-салабыз.
Сабантуйга җыелып алабыз да
«Без бөек» дип оран салабыз.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Булдырабыз барсын-барсын да.
Барда утырганда барс та бит,
Песибез без дошман каршында.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Олы агай бирсә күрсәтмә.
Күрсәтмәне үтибез без аны,
Нинди генә афәт күрсәк тә.
Булдырабыз.
Без бит шундый халык:
Риза-бәхил булдык азга да.
Бу тырышлык белән, иншалла,
Ирешербез инкыйразга да.

*2005*

## Егерменче гасыр, хуш инде

Милләтемне хөрлек багларына
Ымсындырган гасыр, хуш инде.

Юындырмый ташлап китәсеңме
Рәсәй дигән шакшы бу илне.

Хуш инде, хуш, егерменче гасыр,
Көрәшләргә безне бәхиллә.
Милләтемнең татлы хыяллары,
Өметләре китмәсен синдә.

Хуш инде, хуш, егерменче гасыр,
ГУЛАГларың алып китсәңче.
«Ансыз гына тыныч яшәгез» дип,
Бәхиллегең биреп китсәңче.

Хуш инде, хуш, бәхиллегең бирче,
Туры карап милләт күзенә.
Мәнсезлекне безнең алып кит тә
Бәйсезлекләр телә син безгә.

«Коммунизм» дигән хыялларда
Адаштырган гасыр, бәхил бул.
Йөрәгемнән чыккан ошбу җырым –
Сиңа укыласы тәһлил ул.

*2001*

## Татар мөгаллимнәренә

Дөньяда көрәш, зилзилә –
Телсез калдылар илләр.
Телсез калган илебезгә
Тел бирик, мөгаллимнәр.

Дөньяда көрәш, зилзилә –
Алышта сыгыла билләр.
Сыгылган билләр сынмасын –
Көч бирик, мөгаллимнәр.

Дөньяда көрәш, зилзилә –
Ирек даулыйлар ирләр.
Ирек даулаган ирләргә
Рух бирик, мөгаллимнәр.

*1999*

## Эчтәлек

Язмышым – шигырьләремдә ................

*Тулпарларым*

Тулпарларым ........................
Рәхмәт, җырларым... ...................
Сау бул инде, балачагым .................
Карт диңгезче җыры ....................
Ялгыз нарат ........................
Кул бирәбез ........................
Олы юл тузаннары ....................
Туган илнең ап-ак нигез ташы ..............
Агымсулар моңсулата... .................
Илне сагыну ........................
Кайтыр юлда ап-ак томан ................
Без – җирнеке ......................
Шоңкар моңы .......................
Гафу сорыйсы бар... ....................

Иске тальян .........................
Төшкән җирләребез ак таш безнең... ...........
Еллар ага... ..........................
Тол буенда ..........................
Хыянәт ............................
Күзге моң ..........................
Янгынчы монологы ......................
Аклык алып булмас инде... .................
Кояш баеганда .......................
Тормыйсыз ла, картлар... ..................
Учак янында уйлану .....................
Мин дөньяның үги улы түгел ................
Тай өйрәткәндә .......................
Дошманыма .........................
Иркенлек иңә күк җаныма .................
Берәүгә мәрсия .......................
Кеше өчен көлмәк ертма, дисең... .............
Безгә, татарларга, барыбер ................
Җиңнәреңне сызган... ....................
Киләчәкне даулау авыр җирдә ...............
Ташландык үлчәвеч .....................
Илле яшем ..........................
Акбүз ат ...........................
Олы сәфәр чыгып барасыз .................
Бишекләр тирбәлә күңлемдә ................
Песнәк ............................
Җир-ана ...........................
Әкият баласы мин ......................
Сагынылды ..........................
Бүген тагын... .........................
Татар җыры .........................
Кайттым бит... ........................
Юл буенда үскән каен ...................
Тастымал ...........................
Балалар паркында .....................
Биекләргә кыен давылда ..................
Бик кайтасы килә... .....................
Бир әле, җил, кодрәтеңне .................
Без авылда үскән егетләр ич... ...............
Вакыт юк ...........................
Тургай үлеме .........................
Карнавал ..........................
Сөю уты ...........................
Чакыр мине биергә .....................
Һай, гомерләр... .......................
Барда такмаклары .....................
Яшьлек язы .........................
Җиләкле аланнар ......................
Татарстан гимны ......................
Бәхетсез ир .........................
Барда түбәтәйләре .....................

*Сабантуй мизгелләре*

Көрәш мәйданында .....................
Ат чабышында ........................
Капчык белән сугыш ....................
Капчык киеп йөгереш ....................
Чүлмәк сугу .........................
Туры баганага менү .....................
Авыш банагага менү ....................
Йомырка йөгертеш .....................
Катыктан тәңкә эзләү ....................
Бер җырлыйсы килә сабантуйда .............
Биисе килә ..........................
Сабантуй беткәч ......................

*Солдат дәфтәре*

Танымыйсызмыни, каеннар? ................
Кычкыр әле, кычкыр, командир... .............

Туган ил кызларына .....................
Тынгысыз төн .........................
Карап йөри хәрби постларны... ..............
Әйдә җырлыйк, туган ....................
Казакъ дустыма .......................
Солдат боткасы .......................
Итек кенә туза, егетләр... ..................
Әдәпсез син, кызый... ....................

*Ил кайгысы*

Исмәле, җил… ........................
Әй, бөек зат рухы, үрсәләнмә... ..............
Сөембикәне чакыру ....................
Судка бирәм! ........................
Этнографик карта янында .................
Кире алу кирәк Казанны! ..................
Кайтавазлар булып тавышың калды... ...........
Колшәриф монологы ....................
Авылдашларыма ......................
Картлык килгәндә ......................
Каз өмәсе ..........................
Әнчек этләр .........................
Югалмабыз .........................
Тимә әле миңа, агымсу... ..................
Без мәңгегә синдә, Барда җире! ..............
Әй, биедек... .........................
Шашкан аю килә өстебезгә ................
Моң бураны .........................
«Таш бәгырь» ........................
Каз каурые .........................
Ялгызлык ...........................
Иртә килдек бугай... .....................
Туган телемә .........................
Карман урманы .......................
Бәйрәмнәр ..........................
Бурычлы кеше зары .....................
Туган авылым сабан туе ..................
Булдырабыз! .........................
Егерменче гасыр, хуш инде .................
Татар мөгаллимнәренә ..................

Литературно-художественное издание

***Ягъфаров*** *Рашит Файзрахманович*

**Мелодия тулпара**

Стихи

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Ягъфәров*** *Рәшит Фәйзрахманович*

**Тулпар моңы**

Шигырьләр

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Г.Ж.Хисмәтуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм
компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.01.2006.Форматы 70×90 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,27 + форз. 0,15. Шартлы буяу-оттиск 6,15. Нәшер-хисап табагы 4,91 + форз. 0,26. Тиражы 2000 д. Заказ З-32. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://tatkniga.ru. e-mail: tki@tatkniga.ru. Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ. 420066.

Казан, Декабристлар урамы, 2.